МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОСУДАРСТВЕННОЕ АВТОНОМНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ИНСТИТУТ РАЗВИТИЯ ОБРАЗОВАНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

# 2019/2020нче уку елында «ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)» һәм «ӘДӘБИЯТ (ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ)» УКЫТУНЫҢ АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# 2019/2020 нче уку елында “ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)” һәм “ӘДӘБИЯТ (ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ)” укытуның актуаль мәсьәләләре

## Методик тәкъдимнәр

Казан
2019

ББК 74.268

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп,
ТРМҮИ Гыйльми советы карары нигезендә басыла

Ректор, педагогика фәннәре докторы Л.Н.Ногманованың
гомуми редакциясендә

**Фәнни мөхәррир:** Шәмсетдинова Р. Р.
**Рецензентлар:** Шаехов М. Р., филология фәннәре кандидаты; Халиков И. И., филология фәннәре кандидаты, ТР мәгариф һәм фән министрлыгының милли белем идарәсе бүлек мөдире.
**Төзүчеләр:** Шәмсетдинова Р. Р., ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты; Фәттахова Р. Ф., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Гыйләҗева Л. Г., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Хадиева Г. В., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы; Гарипова К. Б., ТР Биектау районы Суыксу төп гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы; Юнысова С. Ф., ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге методисты.

2019/2020 нче уку елында “Туган тел (татар теле)” һәм “Әдәбият (татар әдәбияты)” укытуның актуаль мәсьәләләре/ төз.: Шәмсетдинова Р. Р., Фәттахова Р. Ф., Гыйләҗева Л. Г. — Казан: ТРМҮИ, 2019. — 56 б.

*Хезмәт белем бирү оешмаларында эшләүче туган тел (татар теле) һәм әдәбияты (татар әдәбияты) укытучыларына, мәктәп җитәкчеләренә, милли мәгариф хезмәткәрләренә тәкъдим ителә. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы эшчәнлеген билгели торган норматив документлар "Туган тел" (татар теле) һәм "Әдәбият"(татар әдәбияты) уку предметларының базис һәм үрнәк уку-укыту планнарында тоткан урыны күрсәтелә, эш программаларын төзү, проект эшләре, дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру, укучыларны язма эшләргә әзерләү буенча методик тәкъдимнәр бирелә.*

**© ТРМҮИ, 2019**

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ ЭШЧӘНЛЕГЕН БИЛГЕЛИ ТОРГАН НОРМАТИВ ДОКУМЕНТЛАР

Татар теле Россиядә сан ягыннан икенче милләт булган, күбесенчә Татарстан Республикасында яшәүче, шулай ук Россия Федерациясе субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә бергә тупланып (компактлы) яшәгән татарларның туган теле. Бүгенге көндә Россия Федерациясендә туган телне һәм дәүләт телләрен саклау һәм үстерү өчен кирәкле норматив-хокукый база булдырылган, Татарстан Республикасында тиешле оештыру-идарә итү, фәнни-методик, кадрларга кагылышлы шартлар тудырылган. Кабул ителгән норматив документларга нигезләнеп, татар теле һәм татар әдәбияты гомуми белем бирү системасында туган тел һәм туган телдәге әдәбият, шулай ук дәүләт теле буларак мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү оешмаларының 1–11 сыйныфларында өйрәнелә.

Гамәлдәге хокук системасына һәм норматив актларга туры китереп, татар теле һәм татар әдәбияты ФДББС ының «Туган тел» һәм «Әдәбият» предметы кысаларында өйрәнелә һәм бүгенге көндә белем бирү программасында уку планының үзгәрешсез (инвариант) өлешенә кертелгән, республика укучыларының барысы өчен дә мәҗбүри булып санала.

Татарстан Республикасында татар теле һәм татар әдәбияты мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү оешмаларында, урта һөнәри һәм югары белем бирү системасында өйрәнелә. Россия Федерациясе субъектларындагы этномәдәни татар компоненты булган мәгариф оешмаларында татар теле үрнәк төп белем бирү программаларын исәпкә алып мөстәкыйль формалаштырыла торган программаларга һәм түбәндәге норматив документларга нигезләнеп укытыла.

Татарстан Республикасында телләр өйрәнүнең хокукый нигезләре Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының югары норматив документлары белән раслана.

*Россия Федерациясендә гамәлдә булган норматив документлар:*

– Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Законы (Федеральный закон «Об

образовании в Российской Федерации» (29.12.2012, № 273-ФЗ));

– Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халыкларының телләре турында”гы Законы (Закон РФ “О языках народов Российской Федерации” (25.10.1991, № 1807-1, ред. 12.03.2014);

– Россия Федерациясе хөкүмәтенең 996-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясендә 2025 елга кадәр тәрбия бирү үсеше стратегиясе (Стратегия развития воспитания в Российской Федерации на период до 2025 года, утвержденная распоряжением Правительства Российской Федерации) (29.05.2015);

– 2015-2020 елларга федераль мәгариф үсешенең максатчан программасы (Федеральная целевая программа развития образования на 2015-2020 годы);

– Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2014 елның 29 ноябрендә 2403-р номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр дәүләт яшьләр сәясәте нигезләре (Основы государственной молодежной политики Российской Федерации на период до 2025 года, утвержденные распоряжением Правительства Российской Федерации от 29 ноября 2014 г. №2403-р.).

Алда санап кителгән федераль документлар Россия Федерациясендә мәгариф сәясәтенең төп принципларын һәм юнәлешләрен билгелиләр, шулар нигезендә милли мәгариф эшчәнлеге дә тормышка ашырыла. Документларның төп нигезләмәләре укытучыларның илнең инновацияле үсеше таләпләренә туры килгән сыйфатлы белем бирүне тәэмин итүләренә һәм белем бирү системасының милли мәдәниятен һәм региональ мәдәни традицияләрен үстерүгә юнәлдерелгәннәр.

*Татарстан Республикасында гамәлдә булган норматив документлар:*

Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 года № 68-ЗРТ «Об образовании»);

“Татарстан Республикасының дәүләт телләре халык телләре һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыкларның телләре турында”гы Законы (Закон Республики Татарстан от 8 июля 1992 года № 1560 – XII «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» (с учетом новой редакции Закона Республики

Татарстан от 12 июня 2014 г. № 53–3 РТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан»);

“2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы” (25.10. 2013, 794 нче карар);

Татарстан Республикасында 2012-2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында “Дәүләт программасы”;

2016 елның 19 нчы августында ТР Министрлар Кабинетының 570 нче карары нигезендә расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Милли мәгарифне үстерү концепциясе.

Норматив документлар буенча мәгълүматларны түбәндәге сайтлардан табарга мөмкин:

– http://минобрнауки.рф (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы);

– http://www.edu.ru («Российское образование» федераль порталы);

– http://mon.tatarstan.ru (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы);

– http://www.irort.ru (Мәгарифне үстерү институты)

Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары белән төп гомуми белем бирүнең өч федераль дәүләт мәгариф стандарты (башлангыч гомуми белем бирү — № 373, 06.10.2009 ел; төп гомуми белем бирү – № 1897, 17.12.2010 ел; урта (тулы) гомуми белем бирү — № 413, 17.05.2012 ел) расланды.

Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем стандартлары мәгариф системасына баскычлап кертелә. Башлангыч гомуми белем бирү баскычында федераль дәүләт белем стандарты 2011/2012 уку елыннан гамәлгә кертелде. Ә төп гомуми белем бирү баскычында яңа буын белем бирү стандартына күчү 2015/2016 уку елыннан, урта (тулы) гомуми белем бирү баскычында — 2020/2021 уку елыннан тормышка ашырылачак.

ФДББС — дәүләт аккредитациясенә ия булган башлангыч, гомуми, төп гомуми, урта гомуми, урта һөнәри белем бирү оешмалары тарафыннан төп укыту программаларын гамәлгә куйганда, мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиешле дәүләт таләпләре җыелмасы.

ФДББС түбәндәгеләргә таләпләрне куя:

– төп белем бирү программаларының төзелешенә;

– төп белем бирү программаларын гамәлгә кую шартларына;

– төп белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә.

Бу таләпләр белем бирүнең һәр баскычында укучыларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен искә алып үтәләләр.

**ФДББСның методологик һәм эчтәлек нигезләре түбәндәге документларда чагылыш таба:**

– “Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары Концепциясе" (“Концепция федеральных государственных стандартов общего образования”);

– "Гомуми белем бирү эчтәлегенең федераль үзәге” (“Фундаментальное ядро содержания общего образования”/ под ред. В. В. Козлова, А. М. Кондакова. — М.: Просвещение, 2009);

– “Россия гражданины шәхесен рухи-әхлакый яктан үстерү һәм тәрбияләү Концепциясе” (Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина России: учебное издание / А. Я. Данилюк, А. М. Кондаков, В. А. Тишков. — М.: Просвещение, 2010).

Әлеге документлар белән Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән Министрлыгы сайтында “Федераль дәүләт белем бирү стандартлары” бүлегендә танышырга мөмкин: http://минобрнауки.рф/документы/543.

## ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ҺӘМ ӘДӘБИЯТНЫ УКЫТУ

Татар телен туган тел буларак укыту ил күләмендә татар теленең саклануын һәм үсешен тәэмин итә, татар халкы вәкилләренә аны функциональ куллану мөмкинлеген һәм шартларын тудыра, ил гражданнарының Конституция нигезендә туган телдә белем алуга булган хокукын тәэмин итә. Туган тел буларак татар теленә өйрәтү туган телдә иркен сөйләшә алуга, аны төп аралашу чарасы итеп куллана белүгә, әхлакый-этик нормаларны үзләштерүгә, туган телнең эстетик кыйммәтенә төшенүгә; татар теленең төзелеше, системасы хакындагы белемнәрне һәм аның кулланылыш кагыйдәләрен үзләштерүгә, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итүгә, татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләренә якынаюга, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, толерантлык, мәдәниятара аралашу осталыгы кебек универсаль күнекмәләр булдыруга юнәлтелгән.

Мәктәптә укытыла торган “Татар теле” һәм “Татар әдәбияты” предметлары үзара тыгыз бәйләнештә тора. Татар әдәбиятын укыту татар телен туган тел буларак өйрәтү белән килештерелә.

Татар әдәбияты тормышны танып белү һәм чынбарлыкны кабат тергезү чараларының берсе булып тора — сәнгатьле тасвирлау алымнары ярдәмендә әдәби дөнья сурәте барлыкка китереп, ул аңа карата билгеле бер мөнәсәбәт тудыра; эмоциональ тәэсир итү көченә ия. Татар әдәбияты ул мөһим милли-мәдәни кыйммәтләрне, фикер-карашларны, рухи-әхлакый күзаллауларны үзендә туплап, татар халкының тормыш фәлсәфәсен төшенүгә һәм үзләштерүгә, милли үзаң һәм үзбилгеләнеш калыплашуга китерә, шулай ук гомумроссия гражданины буларак формалашуга да ярдәм итә.

Гуманитар фәннәр арасында әдәбият шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсешенең дәрәҗәсен билгели торган төп предметларының берсе булып санала. Матур әдәбият күп функцияләргә ия һәм ул төрле чорларның иҗтимагый тормышын образлы формада тулы рәвештә чагылдыра ала. Икенче төрле әйткәндә, әдәбият сәнгать чаралары ярдәмендә дөньяның художестволы сурәтен тудыра, аңа билгеле бер мөнәсәбәт булдыра, эмоциональ тәэсир итү көченә ия. Шуңа күрә әдәби әсәрне уку һәм өйрәнү әхлакый

идеаллар турында күзаллауны, кешенең үзенә һәм дөньяга иҗтимагый һәм эмоциональ-кыйммәти мөнәсәбәтен формалаштыра һәм шул исәптән телне үзләштерүдә дә төп җирлек булып тора.

Әдәбият дәресләрендә шәхси үзүсеше өчен әдәбиятны өйрәнүнең әһәмиятен аңлый торган, үз фикерен дәлилле җиткерә, фикерләрен телдән һәм язмача дөрес тәкъдим итә белә торган китап укучы тәрбияләнә. Алай гына да түгел, укучы дөньяны һәм бу дөньяда үзен танып белү өчен даими китап уку ихтыяҗы кирәклеген аңлый.

Матур әдәбият югары әхлакый идеаллар һәм эстетик ихтыяҗларга ия булган рухи яктан бай шәхес формалаштыруда зур роль уйный. Мәктәптә әдәбият укытуның максатлары булып шулай ук әдәби текстны эмоциональ кабул итү, образлы һәм аналитик фикерләүне үстерү, иҗади күзаллау, әдәби әсәр текстларын эчтәлек һәм форма берлегендә үзләштерү, төп тарихи-әдәби мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне өйрәнү, әдәби әсәрләрне уку һәм анализлау күнекмәләрен булдыру тора. Моннан тыш әдәби әсәрләр укучылар телен баетуның, аларның сөйләм культурасын һәм коммуникатив күнекмәләрен формалаштыруның төп чыганаклары да булып тора.

Татар мәктәпләрендә әдәбият фәне атнага бер сәгать укытыла. Әлегә кадәр программага кертелгән әсәрләрнең минимум өлешен саклап калып, калганнары авторы һәм әсәрнең программада торган урыны, аны укучының кабул итү үзенчәлеге ягыннан карап узган уку елында кыскартылып тәкъдим ителгән иде. Бу, үз чиратында, яңа шартларда укучыларның әдәбият фәненнән тиешле югарылыкта мәгълүматлы һәм белемле булуларына ирешү юлларын эзләү һәм табу бурычын куйды:

– беренче чиратта, бу әдәби һәм шуңа бәйле теоретик материалны сайлап алу һәм аны аерым сыйныфларда үзләштерүне өзлексез итеп, алдан планлаштырып оештыру;

– икенче чиратта, дәрестә һәм дәрестән тыш эш алымнарының иң нәтиҗәлеләрен сайлап алу һәм куллану.

Татар мәктәпләрендә әдәбият дәресләрен укыту укучыларның телне белүләре, мөстәкыйль рәвештә текстны укып аңлый, укыган әсәр турында үз фикерләрен җиткерергә сәләтле булуларына нигезләнә. Әгәр бу өлкәдә авырлык бар икән, укытучы иң элек аны бетерү өстендә эшләргә тиеш

була. Бу — уку тизлеген арттыру һәм укылган текстны сөйләп бирү, аның эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирү, әңгәмәдә катнашу, укылган әсәрнең эчтәлегенә мөнәсәбәтле үз фикерен белдерү һәм аны дәлилләп яклый алу. Болар, әдәбиятны фән буларак өйрәнүгә керешкәндә, укучыга куелган иң кирәкле таләпләрнең беренчесе.

Башлангыч сыйныфларда укучыга шушы күнекмәләр бирелеп, аны алга таба әдәбиятны сүз сәнгате һәм фән буларак кабул итәргә әзерлибез. 5–8 сыйныфлар программасы әдәбиятны сәнгатьнең үзенчәлекле бер төре буларак кабул итәргә, әсәр — автор — укучы яссылыгында аңлап, мәктәп укучысы кабул итәрлек дәрәҗәдә әдәбият теориясеннән төп төшенчәләрне дә үзләштерүне үз эченә ала. 9–11 сыйныфларда әдәбият тарихы эзлекле процесс буларак өйрәнелә.

5 сыйныф татар халык авыз иҗаты үрнәкләре (әкият, халык җырлары, мәкаль, әйтем, табышмак, мәзәкләр, бәетләр, легенда һәм риваятьләр), авторларның әкиятләре һәм әдәби әсәрләр (тезмә, чәчмә) белән таныштыруны үз эченә ала. Сайлап алынган әсәрләр укучыларга тел байлыгын арттыруга, аның тәэсир итү көчен аңларга, матурлыгын, нәфислеген, образлылыгын таный белергә өйрәтергә тиеш. Моңа ирешү өчен әдәби геройның тел үзенчәлекләренә, аның холкы, гамәлләре белән сөйләменең уртаклыгына игътибар иттерү, халык авыз иҗаты әсәрләренең һәм әдәби әсәрнең теле арасындагы аермалыкларны билгеләү, чәчмә һәм тезмә әсәрләрдәге сөйләм үзенчәлеген аңларга өйрәтү кирәк. 5 сыйныфта халык авыз иҗаты әсәрләре авторлар әсәрләре белән янәшә куеп өйрәнү, аларның охшаш һәм аермалы якларын ачып бирә алырлык итеп сайланган. Мәсәлән, халык әкиятләрендәге Шүрәле, Зөһрә кыз (әкияттә һәм риваятьтә) образлары Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан әсәрләрендә дә кабатлана. Халык җырлары һәм лирик әсәрләрне, мәзәкләр һәм юмористик шигырьләрне янәшә кую да образ тудыру, хисләрне җиткерү алымнарын чагыштырырга мөмкинлек бирә. Бу халык иҗаты белән әдәбиятның тыгыз бәйләнешен дәлилләргә дә, шул ук вакытта авторлары булган әсәрнең халык иҗатыннан аермасын күрә белергә дә мөмкинлек тудыра. 5 сыйныф, башлангыч сыйныфта өйрәнгәннәргә нигезләнеп, әдәби әсәрне сәнгати яктан кабул итү һәм аның үзенчәлекләрен аңлау, анализлауга керешү чоры. Ул янәшә кую, чагыштыру һәм нәтиҗәләр ясау юлы белән башкарыла. Укучы әсәрнең эчке структур өлешләре, алар арасындагы бәйләнеш

үзенчәлекләрен аңлауга ирешергә тиеш. Укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, әдәби әсәрне өйрәнү укытучы җитәкчелегендә оештырылырга, әсәрнең тиешле урыннарын сыйныфта уку, максатка яраклаштырып алдан әзерләнгән сораулар ярдәмендә материалны бергәләп үзләштерүгә ирешү яхшы. Балаларны кызыксындыру, сөйләмнәрен дөрес оештыру һәм телләрен баету максатында аудио, видео язмаларга мөрәҗәгать итү, аерым әсәрләрне сәхнәләштерү, образларның асылын ачуда рәсем сәнгате ярдәменә таяну уңышлы алым булып тора.

6–7 сыйныф образлар системасы һәм жанр үзенчәлекләрен өйрәнүне максат итә. Халык авыз иҗаты һәм әдәби әсәрләрне өйрәнү янәшә бара. Әдәби әсәрне өйрәнгәндә чор һәм язучы турында кыскача мәгълүмат бирү дә күз алдында тотыла. Шулай ук әдәби әсәрләрне укучының мөстәкыйль үзләштерүенә таяну, язучы биографиясен һәм иҗатын үзләштерүне дә сыйныфтан тыш өйрәнеп башкаларга тәкъдим итү, кыска һәм хәтердә кала торган презентацияләр ярдәмендә җиткерү юлларын сайлау уңышлырак булачак. Дәресләрдә теоретик материалны укучыга аңлатуга, аны ныгытуга басым ясау кирәк. Әдәби әсәрдә эчтәлек һәм форма, идея тематик бөтенлек, образлар системасы, әдәби төрләр һәм жанрлар кебек төшенчәләр, образ тудыру, тәэсирлелек чаралары алгы планга чыгарыла. Әдәби әсәрнең һәр төренә анализ ясый алу күнекмәсе булдырыла. Иҗади эшләрдә образлылык, тел-сурәтләү чаралары, геройларга характеристика, аларның әдәби әсәрдәге урынын билгеләүгә юнәлтелә. Укучыларның иҗади сәләтен үстерүгә басым ясала. Вакыт мөмкинлекләре аз булганлыктан әсәрләрне сан ягыннан киметеп, бер әсәр җирлегендә күбрәк белем һәм анализ күнекмәләренә ирешү күздә тотыла. Укучының хисләрне аңлауда тәҗрибәсе җитмәү, лириканың сурәтләү предметының үзенчәлекле булуы һ.б. бигрәк тә лирик әсәргә анализ ясау үрнәгенә игътибар сорый.

8 сыйныф әдәби әсәрне әдәби чор — автор — укучы бөтенлеге буларак күзалларга өйрәтә. Әдәби әсәрдә тудырылган дөнья сурәтенең авторның фәлсәфи карашлары, гомумкешелек кануннары, чор өчен хас буган иҗат мөмкинлекләре һәм алымнары яссылыгында карау алгы планга куела. Укучы эшчәнлеге чагыштырулар аша авторлар иҗатындагы үзенчәлекләрне һәм охшаш якларны ачыклауга,

шуның нәтиҗәсендә сүз сәнгатенең асылына төшенүгә юнәлтелә.

9–11 сыйныфларда әдәбият тарихы өйрәнелә. Әдәби әсәрне өйрәнү укучының мөстәкыйль укуына нигезләнә. Әмма әсәрне уку өчен алдан укытучы тарафыннан җирлек әзерләнә. Күләмле әсәрләрне уку өчен иң элек максат билгеләнә. Әсәргә анализ ясаганда таяну өчен кирәк булачак эчтәлек, герой һәм аның аерым билгеләре, эш-гамәлләре, әдәби әсәрнең тел-стиль үзенчәлекләре һәм әсәрнең игътибарга алынырга тиешле башка яклары алдан ук искәртеп куела. Язучы биографиясе, эшчәнлеге, чор үзенчәлекләрен өйрәнүдә реферат, презентация, проект формаларына мөрәҗәгать итү нәтиҗәлерәк булачак.

Мәктәптә әдәбиятны өйрәнү аны рухи-эстетик кыйммәт буларак аңларга, әдәбиятның идея-эстетик байлыгын үзләштерергә, классик әдәбият үрнәкләре белән танышырга, әдәби әсәрләрне анализларга һәм бәяләргә өйрәнергә, танылган язучыларның тормыш юлы һәм иҗаты турында күзаллау булдырырга, әдәби әсәрнең образлылыгын аңлау нигезендә коммуникатив күнекмәләр үстерергә һәм камилләштерергә мөмкинлек бирә.

Туган телне (татар телен) укытудагы үзгәрешләр, нигездә, сәгать саны кимүе белән бәйле килеп чыкты. 2019/2020 нче уку елында туган телне (татар телен) һәм татар әдәбиятын укыту буенча эш программалары һәм календарь-тематик планнар ТР МҮИ сайтында РУМО бүлегендә (http://www.irort.ru) урнаштырылган.

Әдәбият гуманитар фәннәр арасында шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсешенең дәрәҗәсен билгели торган төп предметларының берсе булып санала. Матур әдәбият күп функцияләргә ия һәм ул төрле чорларның иҗтимагый тормышын образлы формада тулы рәвештә чагылдыра ала. Икенче төрле әйткәндә, әдәбият сәнгать чаралары ярдәмендә дөньяның художестволы сурәтен тудыра, аңа билгеле бер мөнәсәбәт булдыра, эмоциональ тәэсир итү көченә ия. Шуңа күрә әдәби әсәрне уку һәм өйрәнү әхлакый идеаллар турында күзаллауны, кешенең үзенә һәм дөньяга иҗтимагый һәм эмоциональ-кыйммәти мөнәсәбәтен формалаштыра һәм шул исәптән телне үзләштерүдә дә төп җирлек булып тора.

Әдәбият дәресләрендә шәхси үзүсеше өчен әдәбиятны өйрәнүнең әһәмиятен аңлый торган, үз фикерен дәлилле

җиткерә, фикерләрен телдән һәм язмача дөрес тәкъдим итә белә торган китап укучы тәрбияләнә. Алай гына да түгел, укучы дөньяны һәм бу дөньяда үзен танып белү өчен даими китап уку ихтыяҗы кирәклеген аңлый.

Матур әдәбият югары әхлакый идеаллар һәм эстетик ихтыяҗларга ия булган рухи яктан бай шәхес формалаштыруда зур роль уйный. Мәктәптә әдәбият укытуның максатлары булып шулай ук әдәби текстны эмоциональ кабул итү, образлы һәм аналитик фикерләүне үстерү, иҗади күзаллау, әдәби әсәр текстларын эчтәлек һәм форма берлегендә үзләштерү, төп тарихи-әдәби мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне өйрәнү, әдәби әсәрләрне уку һәм анализлау күнекмәләрен булдыру тора.

Моннан тыш әдәби әсәрләр укучылар өчен телен баетуның, аларның сөйләм культурасын һәм коммуникатив күнекмәләрен формалаштыруның төп чыганаклары да булып тора.

Шуңа күрә мәктәптә татар әдәбияты дәресләренең дә әһәмияте бик зур. Бүген мәктәптә татар телен һәм әдәбиятын өйрәтү торышын исәпкә алып, аны укытуда билгеле бер дәрәҗәдә үзгәрешләр кертелү көтелүе мәгълүм. 2018-2019 нче елларда татар әдәбиятын фән буларак укыту билгеле бер үзгәрешләр кертеп гамәлдәге дәреслекләр буенча башкарылачак.

Туган тел әдәбияты буларак татар әдәбияты курсы укучыларда татар халкының үткәне, менталитеты белән горурлану хисе тәрбияләү, милли традицияләрне, милли геройларны белү һәм хөрмәт итү, дөньяга караш, менталитет, фәлсәфә, татар матди һәм рухи мәдәниятенең үзенчәлекләрен күрсәтү аша милли үзбилгеләнүгә алып бару максатыннан камилләштерүне сорый. Татар әдәбияты әсәрләре тарихи-мәдәни ретроспективада милли идеягә берләшә торган мегатекст тәшкил итәләр. Бу һәр милли мәдәнияткә хас, һәм шуны аңлау туган телдәге әдәбият буларак татар әдәбиятын укыту нигезенә салынган булырга тиеш.

Татар телен туган тел буларак укыту лингвистик компетенция формалаштыруга юнәлдерелгән булырга тиеш. Уку материалын мөмкин булган күләмдә гадиләштереп, үзләштерерлек, лингвистик материалны укучылар сөйләмнәрендә кулланырлык күләмдә бирү максатыннан чыгып укытылырга тиеш. Әлеге максатка ирешү өчен укучыларның аралашу күнекмәләрен формалаштыру, татар

телен туган тел буларак укытуга предметара якын килү, татар теленең татар мәдәнияте һәм тарихы өлкәсендә белем бирә торган башка гуманитар дисциплиналар белән бәйләнешенә игътибарны көчәйтү таләп итела. Укучыларга татар телен өйрәткәндә, мәгълүмати-аралашу технологияләреннән, дидактик материаллар, электрон сүзлекләр, уен-тренажерлардан, театр эшчәнлегенең төрле формаларыннан файдалануны көчәйтергә һәм киңәйтергә кирәк

Телгә өйрәтү һәм әдәби белем бирү практикасында уен, аралашу эшчәнлегенә нигезләнгән, укучыларны план, тезис планы, конспект, доклад, аннотация, инша, эссе язу, әдәби-иҗади эшләр, алдан игълан ителгән темага проект төзү өчен кирәк булган материалларны туплау һәм өйрәтү, мәгълүмати белем бирү мохитендә ориентлаша алу; энциклопедияләр, сүзлекләр, белешмәләр, махсус әдәбият белән эшли белү; китапханә каталоглары, библиографик күрсәткечләрне, интернетта эзләнү системасын куллана алу мөмкинлеге биргән технологияләргә тиешле игътибар бирү сорала.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары буенча дәресләрдә укучыларның метапредмет эшчәнлек нәтиҗәләре дә бәяләнергә тиеш. Ә метапредмет күнекмәләрне булдыруның иң эффектив юлы — ул дәресләрдә яки дәресләрдән соң проект эшчәнлеген оештыру. Дөнья күләмендә алдынгы нәтиҗәләргә ирешкән илләрнең, аерым алганда Сингапур, Финляндиянең мәгариф системасында проект эшчәнлегенә зур урын бирелүе шуның белән аңлатыла.

Проект методын куллану шулай ук татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укучылар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч итәргә ярдәм итә, туган яки дәүләт теле буларак өйрәтелгән дәресләрдә мотивацияне арттыра, игътибарны җәлеп итәргә һәм тотып торырга булыша. Хәзерге заман баласының мәктәптәге дәресләргә караганда күпкә кызыклырак шөгыльләре бихисап, татар теле укытучысы аларны үз файдасына бора алган очракта зур уңышка ирешәчәк.

Проект эшчәнлеген башлатып җибәрү өчен нәрсә кирәк соң? Беренче чиратта, проектны гамәлгә куючы (укучы) һәм аның белән җитәкчелек итүче (укытучы) бу өлкәдә билгеле бер мәгълүматка ия булырга тиеш: проект нәрсә ул, ничек төзелә, ничек бәяләнә, нинди файда китерә һ.б. Икенчедән, җитәкче белән башкаручылар арасында, шулай ук укучылар арасында аралашу, коммуникация җайланган булырга тиеш, чөнки

яхшы проект — ул һәрвакыт диярлек төркем эшенең җимеше. Бары тик бердәм, үзара дус һәм аңлашучан команда башкарган проект кына уңышка ирешә. Өченчедән, барлык башкаручылар да бу эшкә тугры булырга, эшнең нигезен һәм идеясен аңларга, аны ахырга кадәр алып барырга ниятле булырга тиеш. Соңгы шарт сакланмаган очракта теләсә кайсы проект үзенең ахырына — нәтиҗәле продуктына ирешә алмый калачак.

Һәрбер проектның төше, башлангыч ноктасы — ул проблема, шуңа күрә аны сайлаганда аеруча игътибарлы булу таләп ителә. Ул җитәкче өчен генә түгел, ә укучылар өчен дә кызыклы, заман өчен актуаль, башкаручыларның дәрәҗәсенә туры килерлек һәм әлеге дәрес темасына бәйле булырга тиеш.

Проект, һәр уйланылган эш кебек, берничә этаптан, адымнан тора. Аларны эзлекле һәм җиренә җиткереп башкарган чакта гына яхшы нәтиҗәгә ирешеп була. Проект эшчәнлеге исә 4 этапта башкарыла: концепция төзү, планлаштыру, тормышка ашыру һәм рефлексия ясау.

Беренче, концепция төзү этабында проектның төп максатлары һәм бурычлары билгеләнә, алар конкрет, үлчәрлек, вакыт ягыннан чикле һәм ирешерлек булырга тиеш. Бу адымда шулай ук проектка янаган куркынычлар һәм чикләүләр, кирәкле кешеләрне һәм башка материаль ресурсларны табу ысуллары уйлап куела.

Алдагы этапта уйланылган барлык мәгълүмат икенче, планлаштыру этабында конкрет вакыт белән башкаручыларга беркетеп куела. Бу адымда проектны гамәлгә ашыручылар командасында рольләрнең дөрес бүленүенә, куркыныч һәм чикләүләр белән идарә итүгә зур әһәмият бирелергә тиеш. Проектның кәгазьгә язылган планы никадәр тәфсилле булса, проектның уңыш белән тәмамлану мөмкинлеге шулкадәр зуррак.

Бу этаптан соң проектны тормышка ашыру дәвамында җитәкченең башкаручыларны даими контрольдә тотуы, атналык хисап алып баруы, күзгә-күз яки онлайн күрешүе таләп ителә. Болар киләсе проектлар башкарганда үсеш зоналарын билгеләргә, өстен яки кимчелекле якларны вакытында күреп алырга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, башкаручылар проектның арадаш нәтиҗәләрен презентацияләргә, якларга, тәкъдим итәргә әзерләнә. Бу чыгышлар үсеп килгән проектка өстәмә ресурслар җәлеп итәргә һәм гомуми концепцияне конкретлаштырырга булыша,

ә укучыларда чыгыш ясау һәм үз фикерен дәлилли белү күнекмәләре үстерелә.

Рефлексия этабында проектның җитәкчесе дә, башкаручылар да үтәлгән проектның нәтиҗәләрен чыгаралар, уңай һәм тискәре моментларны искә алып, бергәләп аларны төзәтү юлларын эзлиләр. Бу этапта шулай ук укытучы укучыларының эшләрен алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяли, аңлата, үстерү һәм төзәтү юлларын күрсәтә.

Яңа дәреслекләр, яңача төзелгән программалар буенча эшләгән һәр укытучы үз укучыларына проектлар эшләтә. Алар зур яки кечкенә, индивидуаль рәвештә яки команда белән бер атна яки бер чирек дәвамында башкарылырга мөмкин. Ләкин башкаручыларга да, җәмгыятькә дә, татар теленең үсешенә дә аутентик проектлар күбрәк файда китерә, чөнки мондый проектлар дәрес кысаларында гына калмый, аларның нәтиҗәләрен тормышта күрергә һәм кулланырга була.

Уңышлы укытучыларның бай тәҗрибәсеннән күренгәнчә, укучылар проект эшенә бик яратып тотыналар, аеруча аның темасын һәм ахыргы продукт төрен үзләре сайлап алган очракта. Шуңа күрә дәресләрдә укучыларга беренче этапта ирек бирергә, аннан соң гына темаларны төзәтергә, командаларны берләштерергә һәм гамәлгә ашыра башларга киңәш ителә. Алда саналган барлык этапларны дөрес һәм эзлекле башкарып чыкканда укучыларны кызыксындырырлык, ата-аналар күңелен яуларлык һәм идарәчеләребезне канәгатьләнедерерлек проектлар башкарып чыгу авыр түгел.

Татар теле дәресләрендә проект методын куллану укучыларда дәрескә һәм татар теленә кызыксыну уятып кына калмый, аларның шәхси, предмет һәм метапредмет белем һәм күнекмәләрен үстерә, мәктәпнең эшен күрсәтерлек нәтиҗәләр бирә, татар дөньясын уңышлы продуктлар белән баета.

2019/2020 нче уку елларында ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының http://mon.tatarstan.ru сайтында урнаштырылган үрнәк программалар, УМКлар, кулланмалардан файдаланырга тәкъдим ителә. ТР Мәгарифне үстерү институты татар теле һәм әдәбияты кафедрасы хезмәткәрләре тарафыннан эшләнгән методик әсбапларда татар телен һәм әдәбиятын укыту буенча файдалы киңәшләр бирелә (Тәкъдим ителгән әдәбият исемлеген кара).

Эш программалары төзү өчен ТР Мәгарифне үстерү институтының http://www.irort.ru сайтында урнаштырылган

эш программалары төзү өчен нигез булырлык методик тәкъдимнәргә мөрәҗәгать итү урынлы булыр.

Татар телен һәм әдәбиятын укытуда өстәмә сәгатьләр урта гомуми белем бирү оешмаларының компонентыннан алынырга мөмкин.

10–11 сыйныфларда татар теле һәм әдәбиятын укыту Татарстан Республикасының мәгариф оешмалары өчен уку планы белән билгеләнгән уку сәгатьләре кысаларында тормышка ашырыла.

## “ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)” ҺӘМ “ӘДӘБИЯТ (ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ)” УКУ ПРЕДМЕТЛАРЫН УКЫТУНЫ ТӘЭМИН ИТӘ ТОРГАН УКЫТУ-МЕТОДИК КОМПЛЕКСЛАРЫНА КҮЗӘТҮ

Мәктәптә туган телне (татар телен) һәм татар әдәбиятын укыту-методик тәэмин ителеше Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган дәреслекләрнең федераль исемлеге нигезендә тормышка ашырыла. 2019/2020 уку елында белем бирү оешмалары ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган "Дәреслекләрнең Федераль исемлеге" боерыгы (28.12. 2018, № 345) нигезендә яңа федераль исемлеккә кертелгән дәреслекләр буенча укый алачаклар.

**Башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Вагизов С. Г., Валитова Р. Г. | Татар теле (Татарский язык) (для обучающихся на татарском языке) | 1 | ГУП РТ "Татарское книжное издатель-ство" | www.tatkniga.ru |
| Гарипова В. А., Шакирова Г. Р. | Татар теле (Татарский язык) (для обучающихся на татарском языке) (в 2 частях) | 2 | ГУП РТ "Татарское книжное издатель-ство" | www.tatkniga.ru |
| Харисова Ч. М., Шакирова Г. Р. | Татар теле (Татарский язык) (для обучающихся на татарском языке) (в 2 частях) | 3 | ГУП РТ "Татарское книжное издатель-ство" | www.tatkniga.ru |
| Ягафарова Р. Х., Асылгараева Р. А. | Татар теле (Татарский язык) (для обучающихся на татарском языке) (в 2 частях) | 4 | ГУП РТ "Татарское книжное издатель-ство" | www.tatkniga.ru |
| Гарифуллина Ф. Ш., Мияссарова И.Х. | Алифба (Азбука) (на рус-ском и татарском языках) | 1 | Издатель-ство "Мага-риф-Вакыт" | http://magarif-vakyt.ru/ |
| Харисов Ф. Ф., Сиразиева Г. Д. | Татарский язык (Татар те-ле) (на русском и татарском языках) | 1 | Издатель-ство "Мага-риф-Вакыт" | http://magarif-vakyt.ru/ |
| Харисов Ф. Ф., Харисова Ч. М., | Татарский язык (Татар те-ле) (на русском и татарском | 2 | Издатель-ство "Мага- | http://magarif- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Панова Е. А. | языках) | | риф-Вакыт" | vakyt.ru/ |
| Харисов Ф. Ф., Шакирова Г. Р., Сагдиева Р. К., Хисматова Л. К. | Татарский язык. (Татар теле) (на русском и татарском языках) | 3 | Издательство "Магариф-Вакыт" | http://magarif-vakyt.ru/ |
| Харисов Ф. Ф., Харисова Ч. М., Сагдиева Р. К., Гарипова В. А. | Татарский язык (Татар теле) (на русском и татарском языках) | 4 | Издательство "Магариф-Вакыт" | http://magarif-vakyt.ru/ |
| Замалетдинова З. И. | Татарский язык (Татар теле): учебник для начальной общеобразовательной школы с татарским языком обучения (на русском и татарском языках) | 1 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |
| Замалетдинова З. И. | Татарский язык (Татар теле): учебник для начальной общеобразовательной школы с татарским языком обучения (на русском и татарском языках) | 2 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |
| Замалетдинова З. И. | Татарский язык (Татар теле): учебник для начальной общеобразовательной школы с татарским языком обучения (на русском и татарском языках) | 3 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |
| Замалетдинова З. И. | Татарский язык (Татар теле): учебник для обучающихся образовательных организаций начального общего образования с обучением на татарском языке (на русском и татарском языках) (в 2 частях) | 4 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |
| Мияссарова И. Х., Гарифуллина Ф. Ш., Шамсутдинова Р. Р. | Алифба (Азбука): учебник для образовательных организаций начального общего образования с обучением на русском языке, для изучающих татарский язык как родной (на русском и татарском языках) | 1 | Издательство "Магариф-Вакыт" | http://magarif-vakyt.ru/ |
| Мияссарова И. Х., Харисова Ч. М. | Татарский язык (Татар теле): учебник для образовательных организаций начального общего образо- | 1 | Издательство "Магариф-Вакыт" | http://magarif-vakyt.ru/ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | вания с обучением на русском языке, для изучающих татарский язык как родной (на русском и татарском языках) | | | |
| Мияссарова И. Х., Файзрахманова К. Ф. | Татарский язык (Татар теле) учебник для образовательных организаций с обучением на русском языке, для изучающих татарский язык как родной (на русском и татарском языках) (в 2 частях) | 2 | Издательство "Магариф-Вакыт" | http://magarif-vakyt.ru/ |
| Мияссарова И. Х., Файзрахманова К. Ф. | Татарский язык (Татар теле) учебник для образовательных организаций с обучением на русском языке, для изучающих татарский язык как родной (на русском и татарском языках) (в 2 частях) | 3 | Издательство "Магариф-Вакыт" | http://magarif-vakyt.ru/ |
| Мияссарова И. Х., Файзрахманова К. Ф. | Татарский язык (Татар теле) в 2 частях: учебник для образовательных организаций начального общего образования с обучением на русском языке, для изучающих татарский язык как родной (на русском и татарском языках) | 4 | Издательство "Магариф-Вакыт" | http://magarif-vakyt.ru/ |
| Фатхуллова К. С. | Татарский язык (Татар теле): учебник для начальной общеобразовательной школы с русским языком обучения (на русском и татарском языках) | 1 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |
| Фатхуллова К. С. | Татарский язык (Татар теле): учебник для начальной общеобразовательной школы с русским языком обучения (на русском и татарском языках) (в 2 частях) | 2 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |
| Фатхуллова К. С. | Татарский язык (Татар теле): учебник для обучающихся образовательных организаций начального общего образования с обучением на русском языке | 4 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | (на русском и татарском языках) (в 2 частях) | | | |
| Хайдарова Р. З., Галиева Н. Г. | Татарский язык: учебник для образовательных организаций начального общего образования (на русском и татарском языках) | 1 | Издательство "Татармультфильм" | http://publishertm.ru/about/ |
| Хайдарова Р. З., Галиева Н. Г., Ахметзянова Г. М. | Татарский язык: учебник для образовательных организаций начального общего образования (на русском и татарском языках) | 2 | Издательство "Татармультфильм" | http://publishertm.ru/about/ |
| Хайдарова Р. З., Ахметзянова Г. М., Гиниятуллина Л. А. | Татарский язык (Татар теле) учебник для образовательных организаций с обучением на русском языке, для изучающих татарский язык как родной (на русском и татарском языках) (в 2 частях) | 3 | Издательство "Татармультфильм" | http://publishertm.ru/about/ |
| Хайдарова Р. З., Ахметзянова Г. М., Гиниятуллина Л. А. | Татарский язык (Татар теле) учебник для ОО с обучением на русском языке, для изучающих татарский язык как родной (на русском и татарском языках) (в 2 частях) | 4 | Издательство "Татармультфильм" | http://publishertm.ru/about/ |
| Харисов Ф. Ф., Харисова Ч. М. | Татарский язык (Татар теле): учебник для начальной общеобразовательной школы с русским языком обучения (на русском и татарском языках) | 1 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |
| Харисов Ф. Ф., Харисова Ч. М., Залялиева А. К. | Татарский язык (Татар теле): учебник для начальной общеобразовательной школы с русским языком обучения (на русском и татарском языках) | 2 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |
| Харисов Ф. Ф., Хисамова Ф. М., Харисова Ч. М. | Татарский язык (Татар теле): учебник для начальной общеобразовательной школы с русским языком обучения (на русском и татарском языках) | 3 | ГУП РТ "Татарское книжное издательство" | www.tatkniga.ru |
| Харисов Ф. Ф., Харисова Ч. М. | Татарский язык (Татар теле): учебник для обучаю- | 4 | ГУП РТ "Татарское | www.tatkniga.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | щихся образовательных организаций начального общего образования с обучением на русском языке (на русском и татарском языках) | | книжное издательство" | |

Дәреслекләрнең тулы исемлеге белән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының http://mon.tatarstan.ru сайтына кереп танышырга мөмкин.

Болардан тыш, әлеге сыйныфларда татар телен һәм әдәбиятын укыту буенча электрон дәреслекләр, укытучы өчен методик әсбаплар, эш дәфтәрләре дә төзелгән.

Уку елында, мәктәп китапханәләренең фондларын комплектлаштырганда, белем бирү оешмаларына түбәндәгеләргә игътибар итәргә кирәк:

– дәреслекләрне сайлап алу мәктәпнең төп гомуми белем бирү программалары эчтәлеге белән билгеләнә;

– төп белем бирү программаларын үзләштерүдә дәвамчанлыкны саклау максаты белән төрле линияләргә керә торган дәреслекләрне сайлап алу киңәш ителми.

Педагогик хезмәткәрләргә үзләренең профессиональ вазифаларын башкарган вакытта белем бирү программаларына туры килгән һәм белем бирү турындагы законнар белән расланган дәреслекләрне, уку кулланмаларын, укыту һәм тәрбия бирүнең башка чараларын сайлап алу мөмкинлеге бирелә (2012 елның 29 декабрендә чыккан 273-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә Мәгариф турында”гы Федераль закон п. 4, 3 нче бүлек, 47 маддә).

### Туган телдән дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерләү алымнары (эш тәҗрибәсеннән)

**9 сыйныфта** туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе эше сочинение элементлары белән киңәйтелгән иҗади биремле изложение формасында тәкъдим ителә.

Изложение имтихан бирүчеләрнең тыңланган текстка нигезләнеп, мөстәкыйль рәвештә мәгънәви бөтен, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерланган иҗади бирем башкаруына йөз тота. Киңәйтелгән изложение укучыларның лингвистик компетенциясе (тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алуы, тел һәм сөйләмгә караган белеме, өйрәнгән материалны урынлы куллана белү күнекмәләре, шулай ук танып белү, төркемләү,

татар теле дәресләрендә алган аналитик белем һәм күнекмәләр), тел компетенциясе (лексик, грамматик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклау осталыгы һәм күнекмәләре), коммуникатив (аралашу) компетенциясе (сөйләм эшчәнлегендә продуктив һәм рецептив күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсе) тикшерелә.

## Язма эшне бәяләү критерийлары

*1 нче таблица*

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1** | **Изложениенең эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган **барлык** мәсьәләләр язмада урын алган | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган, **әмма** бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 1 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган, **әмма** бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 0 |
| **ИК2** | **Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә:<br>— логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган;<br>текст кызыл юлларга дөрес бүленгән | 2 |
| | Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә, **әмма** бер логик хата бар **яки** кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган, **әмма** логик хатасы бар (бердән артык) **яки** кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән | 0 |
| **ИК3** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, **ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар | 0 |
| **ИК4** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән **(дәлилгә матур әдәбияттан 2 мисал китергән)** | 4 |
| | Укучы **дәлилгә 2 мисал** китергән, шуларның **берсе матур әдәбиятка** карый | 3 |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, 2 дән ким булмаган дәлил китергән) | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Укучы дәлилгә **1 мисал** китергән | 1 |
| | Укучы әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән, **яки** укучы биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән | 0 |
| **ИК1–ИК4 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл** | | **10** |

**Игътибар!**

Әгәр изложениедә сочинение элементлары булмыйча, текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча (ИК1-ИК4) 0 балл белән бәяләнә.

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге** аерым бәяләнә (2 нче таблицаны кара).

*2 нче таблица*

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | Балл |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2–3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| **ГК1–ГК4, ФК1 критерийлары буенча изложение өчен иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә, **изложениенең күләмен** исәпкә алырга кирәк. Язма эшнең гомуми күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш.

2 нче таблицада китерелгән нормативлар гомуми күләме 200 дән артык сүз булган изложениеләрне тикшерү өчен кулланыла.

Әгәр **изложениенең** гомуми күләме 150–199 сүз булса, ГК1–ГК4 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый:

ГК — 1 буенча орфографик хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда, 1 балл куела;

ГК — 2 буенча пунктуацион хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда, 1 балл куела;

ГК — 3 буенча грамматик хаталар булмаганда 1 балл куела;

ГК — 4 буенча сөйләм хаталары булмаганда 1 балл куела.

Әгәр **изложениенең** гомуми күләме 100 сүздән артмаса, мондый эшләргә ГК1–ГК4 критерийлары буенча 0 балл куела.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл — **20.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0–5 балл — «2» ле билгесе;

6–10 балл — «3» ле билгесе;

11–15 балл — «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучы грамоталылык өчен (ГК1–ГК4 критерийлары) 4 баллдан кимрәк балл җыймаска тиеш. Әгәр укучы ГК1–ГК4 критерийлары буенча 4 баллдан кимрәк балл җыйса, «3» ле билгесе куела.

16–20 балл — «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучы грамоталылык өчен (ГК1–ГК4 критерийлары) 6 баллдан кимрәк балл җыймаска тиеш. Әгәр укучы ГК1–ГК4 критерийлары буенча 6 баллдан кимрәк балл җыйса, «4» ле билгесе куела.

## Дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек этаплары

Укучыларны имтиханга максатчан әзерләү 5 нче сыйныфтан ук башланырга тиеш. Башлангыч сыйныфтан билгеле бер күнекмәгә ия булган укучыларны 5 нче сыйныфка кабул итеп алгач, белем һәм күнекмәләрне үстерү юнәлешендә эш дәвам итә. Мәсәлән, эчтәлек сөйләгән вакытта, җөмләләрне дөрес итеп төзүгә игътибар бирелә. Бер үк җөмләдә яки янәшә

җөмләләрдә кабатлаулардан арыну, сүзләрнең синонимнарын куллану күнекмәләре өстендә эшләү оештырыла, сүзлек диктантлары язган вакытта (һәр дәрестә диярлек языла), синонимнар таптырыла. Бу сөйләм нормалары үтәлеше буенча югары балл җыюга ирешергә ярдәм итә. (ГК4). Орфографик сүзлекләр белән эшләү уңай нәтиҗә бирә. 5 нче сыйныфтан ук сүзлек диктантларының дөреслеген сүзлектән карап тикшерү сүзләрнең язылышын хәтердә калдырырга ярдәм итә, шул ук вакытта сүзлек белән эшләү күнекмәләрен үстерә. Дөрес, башта бу эш шактый күп вакытны ала, соңга таба укучылар кирәкле сүзләрне бик тиз табарга өйрәнәләр. (Имтиханда орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә).

## Изложение язу техникасы

Аудиоязмадан текстны беренче тапкыр тыңлаганда,укучыларның игътибарын аның эчтәлеген һәм авторның фикерен аңлауга юнәлтегез. Тыңлау барышында текст артыннан ук ниндидер язмалар теркәп барырга киңәш итмибез. Укучылар бар көчләрен “нәрсә дә булса” язып алуга сарыф итеп, ишеткәннәрен рәттән язып бара башлыйлар. Шул ук вакытта эчтәлекнең иң мөһим өлеше читтә калырга мөмкин. Текстны тыңлаганда, аның төп темасы, микротемалары, идеясе һәм мәгънәви кисәкләрнең үзара бәйләнеше турында фикер йөртү күпкә нәтиҗәлерәк булачак. Текстны икенче тапкыр тыңлаган вакытта язмаларны теркәп бару күпкә отышлырак. Укучының нәрсә һәм ничек язуы ирекле. Шулай да, ялгызлык исемнәре, даталар, туры сөйләм яки диалог һәм терәк сүзләр язылырга тиеш. Язмалар арасында буш урын калдыру ахырдан өстәмәләр кертергә мөмкинлек бирәчәк. Текстны аңларга бирелгән вакытта (текстны беренче тапкыр тыңлаганнан соң) абзацларның эзлеклелеген (авторның фикер йөртешен, тасвирлауларның бирелешен яки вакыйгалар хронологиясен) билгеләп куярга кирәк. Бу сезгә дөрес итеп план төзергә һәм микротемаларны билгеләргә мөмкинлек бирәчәк. Икенче тапкыр тыңлаганнан соң, язмалар арасындагы буш урыннарны тутырып, текстны хәтерегездә яңартыгыз. Тыңлау барышында ук язмалар алып барып, изложение өстендә эшләүнең икенче юлын сайлап була. Беренче тыңлау барышында мөһим сүзләр, гыйбарәләрне теркәү бара. Мәгълүматны яңадан өстәү мөмкинлеге калсын өчен, җөмләләр арасында буш урын калдырырга кирәк.

Мәгънәви кисәкләрне шартлы билге белән (Z) тамгалап чыгыгыз. Икенче тапкыр тыңлаганда, абзацларга бүленешнең дөреслегенә игътибар итәргә онытмагыз. Гадәттә, текстны икенче тапкыр тыңлау барышында якынча план төзелә яки язмаларга өстәмәләр кертелә. Бигрәк тә, текстның идеясен саклауда мөһим булган дата, өземтә, ялгызлык исемнәренә, таныш булмаган географик атамаларга игътибарлы булыгыз.

## Иҗади бирем буенча методик күрсәтмәләр

Бирем темадан читкә китмичә, үз фикереңне белдереп, иҗади эш башкаруны таләп итә. Шулай да, үзеңнең җавабыңны "килешәм-килешмим" дигән бәяләмә бирү белән генә чикләргә ярамый. Имтихан эшенең бу өлешендә мини-сочинение язудагы шәхси осталык исәпкә алына. Әлеге этапта укучылардан фикерләү камиллекләрен күрсәтә белүләре сорала. Укучының язма эше — тулы текст, шуңа күрә ул текстның барлык билгеләрен үзендә тупларга тиеш. Сочинение тексты мәгънәви кисәкләрдән чыгып, абзацларга бүленә. Абзацларның төп җөмләләре текстның нигезен тәшкил итәләр. Әгәр барысы да дөрес эшләнсә, бу җөмләләрне укыгач, бәйләнешле текст килеп чыгарга тиеш. Абзацларның булмавы, яки, киресенчә, текстның абзацларга артык вакланувы сочинение өчен баллның түбәнәюенә китерә. Сочинение текстын нинди критерийлар буенча бәяләвен алдан белгән очракта, эшнең сыйфаты яхшырак булачак. Шуңа күрә ул критерийлар белән танышу гына җитми, экспертларның имтихан эшендә нәрсә күрергә теләвен төгәл белергә кирәк.

**Критерийларга аңлатма бирү**

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1** | **Изложениенең эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган **барлык** мәсьәләләр язмада урын алган. | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма** бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән). | 1 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма** бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән). | 0 |

**Микротема** — бер фикер белән бәйләнгән, берничә мөстәкыйль җөмләнең эчтәлеген бирә торган кисәк.

| ИК2 | **Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |
|---|---|---|
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә:<br>— логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган; текст кызыл юлларга дөрес бүленгән. | 2 |
| | Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә,<br>**әмма** бер логик хата бар<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар. | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**әмма** бердән артык логик хата<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән. | 0 |

Тыңланган текстны кыскартып, укучы яңа бер текст төзи. Ул мәгънәви яктан бөтен, бәйләнешле булырга тиеш. Шулай ук чыганак текстның да логикасын сакларга тиеш.

**Логик хаталар ул** — текстның һәм аерым җөмләләрнең мәгънәви төзелешендәге хаталар.

– Эзлеклелек һәм мәгънәви бәйләнеш бозылганда барлыкка килә. (Анда кызның бөтенләй таныш булмаган кешене үз өенә чакырып, аңа кунакчыллык күрсәтеп, нык ярдәм итә).

– Фикерләү рәвеше эзлекле түгел. (Ул ишекне ябып чыгып китте. “Улым, мин тиздән кайтырмын,” — диде.)

– Җөмләләр арасында бәйләнеш булмау яки аларның тәртибе бозылу. (Үпкәсенә чәчәк исе тулды. Кат-кат кочаклады.)

– Мәгънә аңлауны авырлаштыра торган төрле структуралы җөмләләр куллану.

– Уңышсыз бетем (икеләтелгән нәтиҗәләр).

**Кызыл юл (абзац)** — яңа фикернең башлануын белдерә. Һәр аерым тема, күренеш һәм мәсьәләгә караган өзек кызыл юлдан башлана.

**Абзац** — микротеманың күрсәткече, шуңа күрә, изложение текстын укыганда, интонацион паузаларга игътибар итәргә кирәк.

| ИК3 | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
|---|---|---|
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, **ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар | 0 |

**Текст төзелеше: башлам (кереш өлеш), төп өлеш, йомгак.**

| ИК4 | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
|---|---|---|
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (**матур әдәбиятка караган 2 дәлил-мисал** китергән) | 4 |
| | Укучы **2 дәлил-мисал** китергән, шуларның **берсе матур әдәбиятка** карый | 3 |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, 2 дән ким булмаган дәлил китергән) | 2 |
| | Укучы **1 дәлил-мисал** китергән | 1 |
| | Укучы әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән, **яки** укучы биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән | 0 |

## Сочинениеләрнең якынча тематикасы һәм әдәби әсәрләрдә чагылышы

Табигать һәм кеше:

— кешенең табигатькә йогынтысы, мөнәсәбәте; табигатьнең кешегә йогынтысы;

— табигатьне саклау проблемасы (Ф. Садриевның “Таң җиле”романы, Н. Фәттахның “Итил суы ака торур”романы).

*Ф. Садриевның “Таң җиле”әсәрендә автор тарафыннан кешенең табигатьтән аерылгысыз булуына ишарә ителә. Тормышы, бәхете китек чакларда, кешеләр арасында урын тапмаган хәлләрдә Нуриәсма таңнарда кояш чыгышын карарга чыга торган булган икән. Ул аннан киләчәгенә хәер-фатиха сорап яшәгән.*

*Нурихан Фәттах ”Итил суы ака торур” романында төрле йолаларны, гореф-гадәтләрне сурәтләүгә киң урын биреп, борынгы бабаларыбызның яшәү рәвешен, дөньяга карашын, теләк-омтылышларын тулы итеп күз алдына бастыруга ирешә. Әдип кеше белән табигать бәйләнешен тирән лиризм белән сурәтли.*

Гаилә, балачак, үсмер чак. Гаилә мөнәсәбәтләре. Туган җир. (Г. Бәшировның “Туган ягым — яшел бишек” повесте, Г. Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар”повесте, Ш. Хөсәеновның “Әни килде” драмасы).

*“Туган ягым — яшел бишек”әсәрендә Гомәр Бәширов үзенең күңелле балачагын сурәтли. Күккә ашкан таулар артыннан, үзенең алтын күлмәген киеп, көн дә табигатьне сәламләүче кояшны, аның яктысында җемелдәүче чык тамчыларын, шулай ук авылның бөтен мәшәкатен күреп үсә Гомәр.*

*Әлеге әсәрдә Г. Бәширов балачак образына бәйләп, туган авылын, татар халкының ел саен үткәрелеп килә торган изгедән-изге йолаларын, бәйрәмнәрен нечкәләп сурәтли, аңа мәхәббәтен белдерә.*

*Г. Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар”әсәрендә яшьләр арасында гаилә мәсьәләсенә җиңел карау күренешләре сурәтләнә. Искәндәр, үз мәнфәгатьләрен өстенрәк куеп, хатынына һәм балаларына авырлык китерә, җаваплылыктан кача.*

*Шәриф Хөсәеновның “Әни килде” драмасында үзәктә Ана образы тора. Ул гомере буе туган иленә, халкына хезмәт иткән, балалар тәрбияләп үстергән, хәләл көче белән яшәгән. Балаларын да илгә файдалы, укымышлы итеп үстерергә тырышкан, ире белән дус-тату яшәгән.*

Мәгариф һәм фән. Кеше тормышында мәктәп, укытучының роле. (М. Акъегетнең “Хисеметдин менла” повесте, М. Мәһдиевнең “Без — кырык беренче ел балалары” повесте).

*Муса Акъегетнең “Хисаметдин менла”әсәрендә төп герой үзен халыкны агарту эшенә багышлаучы уңай персонаж итеп сурәтләнә. Хисаметдинның бу эшчәнлеге авылда балалар укытуында һәм, тирә-яктагы авылларга чыгып, фән китапары таратып йөрүендә күренә.*

*М. Мәһдиевнең “Без — кырык беренче ел балалары” повестенда балалар педагогия училищесына укырга, белем алырга киләләр һәм бик күп авырлыкларга дучар булалар. Араларында шуклары, тәртипсезрәкләре булса да, алар белем алу өчен теше-тырнагы белән тырышалар. Авыр сугыш еллары да максатларына ирешү юлында киртә була алмый. Алар белемнең киләчәктә үзләренә бик кирәк булачагын бөтен тулылыгы белән аңлыйлар.*

Кешенең күңел дөньясы:

— комсызлык, акчага табыну, саранлык (Г. Камалның “Банкрот” комедиясе, З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы).

*Галиәсгар Камалның “Банкрот” әсәре татар җәмгыятендәге милли буржуазиянең бер катламы булган сәүдәгәрләрдән, аларның табыш алу өчен теләсә нинди түбәнлекләргә дә әзер булуыннан усал итеп көлә, аны фаш итә.*

*Автор кешенең акчага, байлыкка омтылуын, акча алдында кол булуын күрсәтә, байлык өчен хәтта җинаять кылырга да әзер булуын ача. Сираҗетдиннәр җәмгыятендә бар нәрсәне сатып алып була, “намус”, “вөҗдан” кебек төшенчәләр онытылган, кешеләр түбән җанга әйләнгән, һәммә нәрсә күрәләтә алдауга корылган, тормыш законы булып әверелгән.*

*З. Бигиевның ”Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә” әсәрендә Габденнасыйр эчкерле, намуссыз, үз теләгенә ирешү өчен, теләсә нинди түбәнлеккә төшәргә әзер кеше итеп бирелә.*

— Көнчелек (Г. Сабитов “Тәүге соклану” хикәясе, Ф. Хөснинең “Йөзек кашы” повесте).

*Әхлак тәрбиясе — бүгенге тормышта иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Ул кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтендә, ата-анасына, туганнарына, күршеләренә, хезмәттәшләренә һәм башкаларга булган мөнәсәбәте чагыла. Ул безгә борын-борыннан, әби-бабаларыбыздан мирас булып калган. Әхлак мәсьәләсен күтәргән әсәрләр әдәбиятта һаман очрап тора. Шундый әсәрләрнең берсе — Ф. Хөснинең “Йөзек кашы” повесте.*

*Әсәрдә Госман, Айдарның дусты булып йөрсә дә, аның үзеннән өстен сыйфатларын күреп, көнләшү хисләре кичерә. Җае туры килгәндә, аңа нинди дә булса бер начарлык эшләми калмый. Андагы көнчелек, мәкерлек, хөсетлек шул дәрәҗәгә җитә — Айдарга Вәсилә турында гайбәт, ялган сүз әйтә, аны сөйгәненә тугры булмауда гаепли һәм дәлилгә «Вәсилә» дип язылган йөзекне күрсәтә. Айдардагы кызулык, Госмандагы мәкер, хөсетлек ике кешенең тормышын, бәхетле киләчәген, мәхәббәтен җимереп ташлый. Госман — әнә шулай кешеләрнең бәхетсезлегеннән тәм табучы, сөйкемсез, ямьсез күңелле егет. Мондый кешеләр үзләре дә рәхәт күрмиләр, башкаларга да рәхәт күрсәтмиләр.*

*Г. Сабитовның “Тәүге соклану” хикәясендә Хәниф иптәшенең бәхетеннән, ягъни шатлыгыннан көнләшә,*

*балыгын суга төшертеп җибәрә, янәсе “миңа эләкмәгәч, аңа да булмасын әле”.*

— Гаделсезлек (А. Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” повесте, Ш. Камалның “Акчарлаклар” повесте).

*Ш. Камалның “Акчарлаклар” повестенда балык тотучы эшчеләрне нужа үз авылларыннан, гаиләләреннән куып чыгарган. Алар үзләренең кул көчләре белән гади генә тук тормышка ирешергә дип йөриләр. Балык тоту эшенә яллангач та, аларның өмете зурдан булмый, хыяллары бай булса да, тормыш мөмкинлекләреннән сикерергә теләмиләр: алар айга 40 сум акча эшләп, бала-чагаларына бүләк алып кайта алсалар, шуңа канәгать булалар, ләкин бу — тәмле хыял гына булып кала. Аларга яшәү һәм эшләү шартлары бирелми, капиталистлар аларны изәләр, җәберлиләр.*

*А. Гыйләҗевнең “Җомга көн, кич белән...” әсәрендә Бибинурның фаҗигале үлеме — коточкыч гаделсезлек. Мондый гаделсезлеккә, күңел сукырлыгына юл куярга ярамый.*

— Нәфрәт, намус, оят, үз-үзеңне ярату (Г. Камалның “Банкрот” комедиясе, Ф. Яруллинның “Ак төнбоек” хикәясе, Ш. Хөсәеновның “Әни килде” драмасы).

*Г. Камалның “Банкрот” комедиясендә автор кешенең акчага, байлыкка омтылуын, акча алдында кол булуын күрсәтә, байлык өчен хәтта җинаять кылырга да әзер булуын ача. Сираҗетдиннәр җәмгыятендә бар нәрсәне сатып алып була, “намус”, “вөҗдан” кебек төшенчәләр онытылган, кешеләр түбән җанга әйләнгән, һәммә нәрсә күрәләтә алдауга корылган, тормыш законы булып әверелгән.*

*Бу тормышта кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен. “Ак төнбоек” хикәясендә Ф. Яруллин җитди мәсьәлә күтәрә. Шөһрәтнең артык масаеп китүе аркасында килеп чыккан каршылыкны сурәтли. Кешегә яхшылык эшләү — әйбәт гадәт, әмма шуның белән гел мактанып, кешенең исенә төшереп, яхшылыгың өчен «хак» сорап тору — гайрәтне чигерә торган ямьсез сыйфат. Шөһрәттән иптәшләре дә читләшә, хәтта бергә уйнап үскән дустын югалта. Монысы инде — Шөһрәт өчен зур җәза.*

*Ш. Хөсәеновның “Әни килде” драмасында Ислам дөньяда яшәр өчен намусның әллә ни кирәге юклыгын белеп алган. Ялган юллар белән документлар юллап, үз дигәненә ирешкән, хөкүмәт ташламаларыннан рәхәтләнеп файдалана.*

— Куркаклык (Ш. Хөсәеновның “Әни килде” драмасы).

*Ш. Хөсәеновның "Әни килде" әсәрендә Исламга хас төп сыйфат — куркаклык. Ул бала чактан ук шундый булган — иптәшен судан коткара алмаган. Сугыш башлангач, тылда качып яткан, үн ел төрмәдә утырган. Ялган документ белән өстенлекле пенсия алып ятудан да оялмый. Җитмәсә, үзенең шундый яшәү рәвеше белән мактана да.*

*Әсәр Ананың балаларына әйтеп калдырган васыяте белән тәмамлана."Кеше булыгыз! Куркак җан булудан сакланыгыз! Кеше куркак булса, үзенең җанын саклап калу өчен, теләсә нинди түбәнлеккә бара. Атасын да, анасын да , хәтта Ватанын да сата!.."*

— Ихтыяр көче булмау, үз-үзеңә ышанмау, үз фикерең булмау (Ф. Әмирханның "Хәят" повесте)

*Ф. Әмирханның "Хәят" повестенда төп герой Хәят үз бәхете өчен көрәшүдән баш тарта. Күңеле белән Михаилга тартылса да, рус дөньясы белән үзе арасында упкын ятканын, язмышының мөселман дөньясы белән аерылгысыз икәнен аңлый башлый, сөйгәнен йөрәгеннән йолкып атарга мәҗбүр була.*

— Җаваплылык (А. Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән... повесте", М. Галәүнең "Мөһаҗирләр" романы).

*Аяз Гыйләҗевнең "Җомга көн, кич белән..." әсәрендә ата-ана һәм балалар арасында мөнәсәбәтләрнең катлаулы булуы сурәтләнә. Ана алдындагы иң изге бурычны оныту ул — кешелексезлек, ди автор. Тормышта чын Кеше булып калырга кирәк.*

*Мәхмүт Галәүнең "Мөһаҗирләр" романында сурәтләнгән Сажидә гаиләнең таянычы, оста оештыручы буларак тасвирлана. Ул иң кыен хәлдән дә чыгу юлын таба алуы белән ирләрдә дә соклану уята. Ул — җаваплы, төпле фикерле, үз бәхете өчен көрәшә торган хатын.*

Әхлаклылык һәм мораль:

— битарафлык (А. Гыйләҗев "Җомга көн, кич белән...", Г. Ибраһимовның "Кызыл чәчәкләр" повесте).

*Бибинурның фаҗигале үлеме — коточкыч гаделсезлек, кешеләрнең битарафлыгы нәтиҗәсе. Мондый гаделсезлеккә юл куярга ярамый. Әхлак кагыйдәләре бозылу һәрвакыт олы фаҗигагә китерә, ди язучы. Шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек кешеләр өчен бик кирәк. Яшәүнең матурлыгы, мәгънәсе шунда. Кеше, нинди генә заманда яшәсә дә, рәхим-шәфкатькә, мәхәббәткә мохтаҗ.*

*Г. Ибраһимовның "Кызыл чәчәкләр" әсәрендә биш дусның язмышы сурәтләнә. Бергә уйнап үскән малайларның дуслыгы сынала. Битарафлык авыр фаҗигаләргә китерә.*

— Мәхәббәт (Ш. Камал "Акчарлаклар" повесте, Ф. Бурнаш "Таһир-Зөһрә" әсәре).

*Җирдә тереклек башлану белән мәхәббәт тә дөньяга килгән. Бу һәркемнең йөрәге аша уза, аны һәрбер кеше үзенчә кичерә. К. Гали "Кыйссаи Йосыф" әсәрендә Йосыф белән Зөләйханың мәхәббәтен мавыктыргыч итеп сурәтли алган. Биредә тугрылыкка, сабырлыкка сокланырлык. Халкыбыз бүгендә яшь парларга Йосыф һәм Зөләйха мәхәббәтен тели икән, бу — язучының әлеге теманы шулкадәрле бөек һәм мәңгелек итә алуының төп дәлиле.*

*Ф. Бурнашның "Таһир-Зөһрә" әсәре безне бүгенге көндә дә дулкынландыра, мәхәббәткә мәдхия булып яңгырый. Татар халкында бер-берсен нык яраткан ике яшь турында "Таһир белән Зөһрә инде" дигән гыйбарә бар. Әсәр геройлары бер-берсен шулкадәр нык яраталар: сөйгәннәре өчен корбан булырга да әзерләр.*

— шәфкатьлелек (Ә. Еники "Әйтелмәгән васыять", Ә. Еники "Ана һәм кыз", Ш. Хөсәенов "Әни килде")

— тугрылык ( Ф. Садриев "Таң җиле", Кол Гали "Кыйссаи Йосыф")

— ялган, алдау (Г. Камал "Банкрот", Г. Рәхим "Яз әкиятләре")

— үз хатаңны тану, үкенү (Ш. Камалның "Буранда" хикәясе, "Сак-Сок бәете", З. Хәкимнең "Телсез күке" әсәре).

Кеше һәм сәнгать: талантлы булу, музыканың кеше тормышында роле (Ә. Еники "Кем җырлады?", А. Гыйләҗев "Язгы кәрваннар", З. Хәкимнең "Телсез күке" әсәре).

*Татар моңы кеше күңелендәге иң тирән хисләрнең юлдашы булып тора. Әмирхан Еникинең "Кем җырлады" әсәрендә үлем көтеп яткан егеткә Җыр, сызлануларын онытып, азга гына булса да, үлемне чигендерә.*

*З. Хәкимнең "Телсез күке" әсәрендә ата-баба телен белү, җыр-моңын өйрәнү Зариф белән Зыятдин өчен җан-рух теләге булып тора. Шуңа да алар өчен "татар җыры" — чикләрне белми торган изге төшенчә. Татар җырын аңлау теләге бар икән, аны җиңәрлек көч юк, чөнки әлеге җырлар ата-баба каны тамган җир ямен, халыкның ачы, фаҗигале язмышын, теләк-омтылышын үзенә сыйдырган. Икесе ике илтөбәктә туып үссәләр дә, Зариф белән Зыятдинда әнә шуны аңлау бар. Ул исә аларны үзара якынайта, туганлаштыра,*

*бер-берсенә ярдәм итүнең намус эше, иман ныклыгы булуын аңлауга китерә.*

**Сугыш: ватанпәрвәрлек, туган илне саклау**

*Татар әдәбиятында сугыш темасын чагылдырган әсәрләр күп. Сугыш елларындагы ачлык, ялангачлык, сугыш кырларында ятып калган корбаннар, фашистлар тоткынлыгында хурлыклы һәм мәсхәрәле үлемен көткән әсирләр язмышы татар язучыларын тетрәндерми калмый, уйланырга мәҗбүр итә.*

*Әмирхан Еникинең "Бала" хикәясендә Зариф чын ир буларак сурәтләнә. Ул кешелек бурычын да, солдат бурычын да җиренә җиткереп үти. Ул үзенең эшләгән батырлыкларын гадәти эш итеп кенә карый, изгелекне күңел кушуы буенча эшли. Сугышта күп нәрсә үзеңнән тора икән бит. Сугыш каршында Зариф көчсез түгеллеген аңлый. Бу хис Зарифны тынычландыра, рухын ныгыта, җиңүгә ышанычын арттыра.*

*"Ана һәм кыз" хикәясендә исә Рәхиләнең эчке табигате бирелә. Сугыш чорының рәхимсезлеге гади бер гаиләдә тасвирлана. Ана авырый, ул сугыштагы улын көтә. Кызына киңәшләрен бирә, гомеренең соңгы көннәрен үткәрүен аңлый. Дөнья белән саубуллашканчы, улын күрәсе килә аның, күңеле белән баласының кайтасына ышана, ләкин насыйп булмый.*

**Туган телне, гореф-гадәтләрне саклау проблемасы**

*Туган тел — тарихның хәзинәсе, рухы, җаны ул. Аның матурлыгы шагыйрьләр, язучылар өчен генә түгел, барыбызга да кирәк.*

*Ә. Еникинең "Әйтелмәгән васыять" әсәрендә Акъәби оныкларының туган телләрен белмәвенә борчыла. "Аһ, бу тел юклыгы!.. Суфиян, юньсез, балаларына, ник ичмасам, әбиләренә дәшә алырлык кына үзебезчә берничә дистә сүз өйрәтмәде икән соң?!" Акъәби балаларына газиз туган телне күз карасыдай кадерләп сакларга кирәк дип васыять әйтеп калдырырга тели.*

**Икмәккә мөнәсәбәт проблемасы**

*Икмәк! Шулай дип авыз тутырып әйттең исә, тәмле исе белән борыннарны кытыклап, өсте алтынга манылган сыман сап-сары, күпереп пешкән ипи күз алдына килә. Икмәкне олылап, безнең халык телендә күпме генә әйтемнәр, хикәяләр тумаган!*

*Г. Бәшировның "Туган ягым — яшел бишек"әсәрендә җирләр кардан арчылгач, Гомәрләр ашлык чәчәргә басуга*

*китәләр. Бу гади генә нәрсә түгел. Аның да үз тәртибе бар. Әнкәйләре иртән иртүк йомыркаларын әзерләп куйган инде. Гомәр белән әтисе бу йомыркаларны кара җиргә сибеп җибәрәләр. Бабайлар шулай эшләгән чакта, иген уңар, иген бөртеге йомырка кадәрле булыр, дип ышанганнар.*

*А. Гыйләҗевның "Язгы кәрваннар" әсәрендә сугыш чорында икмәкнең бик тә кадерле булуы сурәтләнә. "Алабута катнашкан булса да, алда — ризык. Аны олыларга кирәк!.. Кешеләрнең сулыгып-сулыгып ризык сораган ашказаннарына рәхәт җылылык йөгерде, йөзләргә кызыллык белән елмаю чыкты" юлларында ипинең яшәү чыганагы булуы раслана.*

**Китап укуның шәхес буларак формалашуда роле**

*Китап — иң акыллы киңәшчеләрнең берсе. Ул һәр кешегә хезмәттә булыша, кешеләрне бәладән коткара, тормышны танып белергә өйрәтә.*

*Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" әсәре һәркемнең күңеленә якын булган: олысы да, кечесе дә, егет һәм кызы да, укымышлысы да — һәркайсы аннан үзенә рухи азык, көч алган. Олылар сабыр булырга, карчыклар гайбәттән качарга тырышканнар, егетләр һәм кызлар мәхәббәттә тугрылыклы булырга ант эчкәннәр. Поэма һәркемдә киләчәккә ышаныч, якты өметләр уяткан, ил-халык алдында ак йөзле, саф күңелле, намуслы булырга өйрәткән.*

**Эчке һәм тышкы матурлык**
**(Ә. Еникинең "Матурлык" хикәясе)**

*Кешенең рухи байлыгын сурәтләгән әсәрләр исемлегенә Ә. Еникинең "Матурлык" хикәясен кертеп була. Бу әсәрендә язучы баланың анага булган тирән мәхәббәтен, зур хөрмәтен сурәтли. Авырудан ямьсезләнеп калган әнисе өчен улы бер дә уңайсызлык кичерми. Әнисе аның өчен изге, илаһи зат. Егет өчен тышкы матурлык әһәмиятле түгел. Иң мөһиме — кешенең рухи дөньясы бай булсын, уй-хисләре саф, пакь, күңеле чиста булсын.*

**Туган илгә мәхәббәт**

*Мәхмүт Галәүнең "Мөһаҗирләр" романында күчеп китү һәм яңа тормыш кору вакыйгалары урын алып тора. Бу исә кеше өчен туган җир кадере мәсьәләсен алга куя. "Кеше бары тик туган җирендә генә бәхетен таба ала" дигән нәтиҗәгә китерә автор.*

***Зөлфәт Хәкимнең "Телсез күке" әсәрендә күтәрелгән проблемалар:***

*– бәхетле булу, яшәү мәгънәсен эзләү, яхшылык һәм явызлык, яхшылыкка яхшылык белән җавап бирү;*

*– туган телне, җыр-моңны саклап калу, үз яшәү рәвешеңә тугры булу, буыннар арасындагы рухи бәйләнешне саклау;*

*– хакимият һәм кеше арасындагы мөнәсәбәт;*

*– мәхәббәт, гаилә, тормыштагы максат һәм аңа ирешү юллары, үз урыныңны табу.*

*Тормышы никадәр генә катлаулы, каршылыклы булмасын, кеше үз асылына тугрылыклы булып калырга, изге гамәлләр кылып яшәргә тиеш. Ул шул вакытта гына тынычлык таба.*

*Милли моң. Татар җыры — ата-баба телен белү, җыр-моңын өйрәнү ике герой өчен дә җан-рух теләге булып тора. Шуңа да алар өчен "татар җыры" — чикләрне белми торган изге төшенчә. Татар җырын аңлау теләге бар икән, аны җиңәрлек көч юк, чөнки әлеге җырлар ата-баба каны тамган җир ямен, халыкның ачы, фаҗигале язмышын, теләк-омтылышын үзенә сыйдырган. Икесе ике ил-төбәктә туып үссәләр дә, Зариф белән Зыятдинда әнә шуны аңлау бар. Ул исә аларны үзара якынайта, туганлаштыра, бер-берсенә ярдәм итүнең намус эше, иманныклыгы булуын аңлауга китерә.*

***Фоат Садриевның "Таң җиле" әсәрендә күтәрелгән мәсьәләләр:***

*– хәмер эчүнең зур афәткә әверелүе;*

*– кешеләр арасында үзара ышаныч югалу;*

*– дингә карашның көлке һәм куркыныч төсмер алуы;*

*– татар халкына хас сыйфатларның югала баруы;*

*– телнең сакланышы;*

*– буыннар арасында рухи бәйләнеш.*

*Әдип халкыбызның гасырлар дәвамында тупланган әхлакый яшәү рәвешен якларга, намуска тугры калырга чакыра. Кешенең үз-үзе белән канәгать булуы, шатлык кичереп яшәве бары тик иманлы, гадел, тугры, ялганга баш бирмичә яшәүдә дигән нәтиҗәгә китерә.*

*Нуриәсма саф күңелле, кешеләргә матурлык, гаделлек өләшә.*

| | |
|---|---|
| **ИК1-ИК4 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл** | **10** |

| | |
|---|---|
| **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча изложение өчен иң югары балл** | **10** |

## Грамоталылык буенча белемнәрне бәяләү

**Грамматик хаталар:** кайбер грамматик хаталарга түбәндәгеләрне кертеп карарга була: сүз ясалышында хаталар җибәрү, сүзтезмә яки җөмләләрне дөрес төземәү, сүз формаларын дөрес кулланмау; бер килеш кушымчасы урынына икенчесен язу, тартым яки зат-сан кушымчаларын бутау, сыйфат фигыль формасын дөрес сайламау; җөмлә кисәкләрен бәйләүдәге төгәлсезлекләр, фигыль заманнарын бутау, туры сөйләм өлешләрен бутау.

**Сөйләм хаталары:** кайбер сөйләм хаталарына түбәндәгеләр керә: паронимнарны аермау (**паронимнар** — яңгырашы ягыннан якын, бер тамырдан булган сүзләр; алар бер үк сүз төркеменә карыйлар, әмма төрле мәгънә белдерәләр: абстрактлык — абстракция, экономия — экономика, диктант — диктат, адресант — адресат); синонимнарны дөрес сайламау, антитеза төзегәндә, антонимнарны дөрес кулланмау; фразеологизмнарныңобразлы төзелешен бозу; артык сүзләр куллану; плеоназм; тавтология; сүзләрне кабатлау; синтаксик конструкцияләрнең ярлылыгы; алмашлыкларны дөрес кулланмау.

## Сочинениенең фактик төгәллеге

**Фактик хаталар:** әсәр исемнәрен, вакыйгаларны, чорны (гасыр, ел, ай, көн һ.б.) персонажларның (герой, катнашучы яки аның турында нинди дә булса фикер әйтүче кешенең) исем һәм фамилияләрен, цитаталарның чыганакларын бутау; техник төгәлсезлекләр.

## Татар мәктәбендә укучы татар балаларына әдәбияттан тәкъдим ителә торган әсәрләр минимумы

### 5 сыйныф

«Ак бүре» әкияте (кыскартып).
«Шәһәр ни өчен Казан дип аталган» риваяте.
«Зөһрә кыз» легендасы.
«Иске кара урман» җыры.
«Сак–Сок» бәете.
Г. Тукайның «Шүрәле» әкияте.
Г. Тукайның «Пар ат», «Туган җиремә» шигырьләре.
Ф. Әмирханның «Ай өстендә Зөһрә кыз» хикәяте.
М. Гафуриның «Сарыкны кем ашаган?» мәсәле.
Ш. Галиевнең «Һәркем әйтә дөресен» шигыре.
Ф. Яруллинның «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» шигыре.

### 6 сыйныф

«Алып кешеләр», «Җил иясе җил чыгара» мифлары.
К. Насыйриның «Әбүгалисина» повесте.
Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе.
Г. Рәхимнең «Яз әкиятләре» хикәясе.
Дәрдемәнднең «Видагъ» шигыре.
С. Рәмиевнең «Уку» шигыре.
Г. Камалның «Беренче театр» комедиясе.
Г. Тукайның «Исемдә калганнар» истәлеге.
Р. Батулланың «Имче» хикәясе.
Һ. Такташның «Пи-би-бип» шигыре.
М. Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә» балладасы.

### 7 сыйныф

«Идегәй» дастаны (өзекләр).
Г. Тукай «Милләткә» шигыре.
Н. Думавиның «Яшь ана» хикәясе.
Г. Исхакыйның «Җан Баевич» комедиясе.
Ш. Камалның «Акчарлаклар» повесте (өзекләр).
С. Хәким «Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре.
Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясе.
Ш. Хөсәеновның «Әни килде» драмасы.
Г. Сабитовның «Тәүге соклану» хикәясе.
М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повесте.
Г. Гыйльмановның «Язмышның туган көне» хикәясе.

### 8 сыйныф

Мөхәммәдьярның «Нәсыйхәт» шигыре.
Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» повесте.
М. Гафуриның «Нәсыйхәт» шигыре.
Ш. Камалның «Буранда» хикәясе.
Ф. Әмирханның «Бер хәрабәдә» хикәясе.
Ф. Борнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясе.
Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте.
Һ. Такташның «Алсу» поэмасы.
К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасы.
Ф. Кәрим “Сибәли дә сибәли” шигыре.
Р. Фәйзуллинның «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга...» шигыре.
Т. Миңнуллиннның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасы.
Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте.

М. Әгъләмовның «Каеннар булсаң иде», «Учак урыннары» шигырьләре.

**9 сыйныф**

З. Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы (өзекләр).
Ф. Әмирханның «Хәят» повесте.
Г. Камалның «Банкрот» комедиясе.
М. Галәүнең «Мөһаҗирләр» романы (өзекләр).
Г. Кутуйның «Сагыну» нәсере.
М. Җәлилнең «Җырларым», «Тик булса иде ирек» шигырьләре.
Ә. Еникинең «Кем җырлады?» хикәясе.
Х. Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы», «Киек казлар» шигырьләре.
А. Гыйләҗевның «Җомга көн кич белән» повесте.
Н. Фәттахның «Ител суы ака торур» романы (өзекләр).
Т. Миңнуллинның «Кулъяулык» музыкаль драмасы.
Ф. Садриевның «Таң җиле» романы (өзекләр).
Зөлфәтнең «Тамыр көлләре», «Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигырьләре.

**Кулланылган әдәбият.**

1. Гыйләҗева Л. Г., Хадиева Г. В. Татар теле. 9 нчы сыйныф. Дәүләт (йомгаклау аттестациясенә әзерләнү. Татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләре өчен методик кулланма. — Казан: Ихлас. — 92 бит.

2. Закирҗанов Ә. М., Фәхретдинова Г. М. Әдәбият дәресләре. 9 сыйныф: методик кулланма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. — 211 б.

3. Хәбибуллина З. Н., Гыйләҗев И. Г. Изложениеләр җыентыгы: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче, рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 2-11 нче сыйныфлары өчен. — Тулыл. 2 нче басма. — Казан: Мәгариф, 2003. — 239 б.

## "ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)" ҺӘМ "ӘДӘБИЯТ (ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ" ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА ПЛАНЛАШТЫРГАН НӘТИҖӘЛӘРГӘ ИРЕШҮ

Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандарты белем бирү процессының эчтәлеген яңарту, аның нәтиҗәләрен югары сыйфатлы итү максатын куя һәм шуның нигезендә укытучыларга укучыларда милли кыйммәтләр урнаштыру, белем бирүдә планлаштырылган нәтиҗәләрне һәм универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, бәяләү системасын камилләштерү бурычлары йөкләнә. Укытуда предмет нәтиҗәләрен генә түгел, ә шәхескә бәйле һәм метапредмет нәтиҗәләрен (универсаль уку гамәлләрен) булдыру буенча эш алып барыла. Белем бирү процессында укучыда универсаль уку гамәлләрен формалаштыра алсак, бала мәктәптә алган белем-күнекмәләрне алдагы тормышта да куллана алачак, үз-үзенә ышанган, мөстәкыйль эш итә торган, коммуникатив, рухи дөньясы бай, кешелекле шәхес буларак тәрбияләнәчәк.

"Туган тел (татар теле)" һәм "Татар әдәбияты)" предметларын укытуда шәхескә бәйле нәтиҗәләрне формалаштыру укучыларның түбәндәге сыйфатларга ия булуы белән билгеләнә:

– туган телне (татар телен) шәхеснең интеллектуаль, иҗади *сәләтләрен, әхлак сыйфатларын камилләштерүдә ролен билгели торган татар халкының төп милли-мәдәни кыйммәте итеп тану;*

– *туган телнең (татар теленең) эстетик кыйммәтен аңлау; туган телгә карата тирән ихтирам, аның өчен горурлык хисе барлыкка килү; татар теленең чисталыгын саклау ихтыяҗы булу; татар телендә грамоталы сөйләшергә омтылу;*

– *аралашу* процессында фикерләрне һәм хисләрне иркен белдерү өчен җитәрлек сүз запасына һәм грамматик чараларга ия булу; үз сөйләмеңне күзәтү нигезендә үзбәягә сәләтле булу (рефлексия).

Метапредмет нәтиҗәләре — баланың белем алуга сәләтен һәм алган белемнәрен практикада куллана белү осталыгын булдыра торган универсаль уку гамәлләре комплексы.

Универсаль уку гамәлләре — субъектның яңа социаль тәҗрибәне аңлы һәм актив рәвештә үзләштерү юлы белән

үзүсешкә һәм үзен камилләштерүгә сәләте, ягъни укучының белем алу процессын оештыра алуы.

Универсаль уку гамәлләре системасын түбәндәге компонентлар тәшкил итә:

- шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләре (үзбилгеләнеш, белем алуга әзерлек, белем дәрәҗәсен, танып белү эшчәнлегенә сәләтлелек, әхлакый-этик сыйфатларның камилләшүенә юнәлдерелгән гамәлләр);
- танып-белү универсаль уку гамәлләре (гомумуку, логик, проблема кую һәм аны хәл итү гамәлләре);
- коммуникатив универсаль уку гамәлләре — үзара мөнәсәбәтләрне җайлау һәм уртак нәтиҗәгә ирешү максатында ике яки берничә укучының үзара хезмәттәшлек итүенә корылган эш төрләре:

– *башкаларны тыңлый һәм ишетә белү;*

– *аралашу бурычлары һәм шартларына туры китереп фикерне белдерә алу;*

– *башкаларның фикере белән кызыксыну һәм үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;*

– *үз фикереңне дәлилли белү, тормыштан мисаллар китерү;*

– *укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;*

– *бирелгән текстларның дәвамын сөйли алу, автор фикере белән чагыштыру;*

– *сыйныфташлар каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;*

– *диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;*

– *татар теленең грамматик һәм стилистик нормаларынанигезләнеп, монгологик һәм диалогик сөйләм төзү күнекмәләренә ия булу;*

– *төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;*

– *төрле карашларны тыңларга әзер булу һәм күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;*

– *гомуми эшне оештыруда инициатива күрсәтү (эшлекле лидерлык);*

– *сораулар ярдәмендә мәгълүматны таба алу;*

– *әңгәмәдәшнең үз-үзен тотышы белән идарә итү — аның гамәлләрен күзәтү, төзәтү һәм бәяләү, ышандыра алу;*

– *эшлекле мөнәсбәтләр урнаштыру, нәтиҗәле хезмәттәшлек итү;*

– *төркемдә конфликтсыз эшләүне тәэмин итү, үзара ярдәмләшү;*

– *әңгәмәдәшләргә* ихтирамлы караш булу.

- регулятив универсаль уку гамәлләре (уку мәсьәләсен кую, планлаштыру, фаразлау, контроль, коррекция, бәяләү, үзрегуляция).

Дәрестә әлеге универсаль уку гамәлләренең дүрт төре дә, һичшиксез, тигез дәрәҗәдә формалаштырылырга тиеш.

Предмет нәтиҗәләренә таләпләр:

– *сөйләм эшчәнлеге төрләре камилләшү;*

– *татар теленең коммуникатив, эстетик мөмкинлекләреннән оста файдалану;*

– *тел турында фәнни белемнәргә ия булу һәм аларны системалаштыру; тел бүлекләре һәм берәмлекләре арасындагы бәйләнешләрне аңлау; лингвистиканың төп төшенчәләрен, телнең төп берәмлекләренһәмграмматик категорияләрен үзләштерү;*

– *сүзне төрле яклап анализлау, сүзтезмәләргә һәм җөмләләргә синтаксик* анализ ясау, шулай ук текстка күп аспектлы анализ ясау күнекмәләре формалашу.

Актив аралашуга корылган күнегүләр аша телнең грамматик нормаларын үзләштерү, лексикасын өйрәнү һәм актив сөйләмдә грамоталы итеп куллану тормышка ашырыла. Бу дәресләрнең эчтәлегендә текстны уку, текст буенча эшләү буенча күнегүләр системасы өстенлек итә: текст буенча сорауларга җавап бирү, эчтәлеген сөйләү, ахырын уйлап язу; темасын, микротемаларын билгеләү; планын төзү, конспектлау, аннотация язу, анализлау. Тексттан соңгы этапта текст буенча диалогик, монологик сөйләмгә чыгу оештырыла: телдән һәм язма, монологик (хикәяләү, тасвирлау, фикерләү) һәм диалогик сөйләм төзү эшчәнлеге башкарыла. Коммуникатив ысул лексик берәмлекләрне һәм аларның грамматик формаларын билгеле бер ситуацияләргә бәйләп өйрәтүне таләп итә. Чынбарлыкта кешеләр, аралашу сферасыннан чыгып, бер-берсе белән хәбәрләшәләр һәм моның өчен кирәкле тел берәмлекләреннән файдаланалар.

Яңа таләпләр укытучының позициясен үзгәртте, ул: укучыларда фәнне өйрәнүгә уңай мотивация булдыра, аларның эшчәнлеген мөстәкыйль планлаштыруны оештыра, укучыларны куелган мәсьәләләрне мөстәкыйль чишү юлларын эзләүгә этәрә, иҗади сәләтләрен үстерү өчен уңай шартлар тудыра, белемнәрне үзләштерүгә иҗади якын килергә,

мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә, үзбәягә, үзконтрольгә өнди, укучыларның шәхси сәләтләрен, үзенчәлекләрен күреп, уңай бәяли, белем алуда яңа казанышларга рухландыра. Димәк, укытучы традицион рәвештә белем бирүче генә түгел, ул — җитәкче, оештыручы, киңәшче, дус. Укучы исә дәрестә актив катнашучы, ул: уку-танып белү эшчәнлегенә максат куя һәм аңа ирешергә тырыша, дәреснең эш планын төзүдә катнаша һәм нәтиҗәләрен бәяли, яңа белемнәрне укытучы җитәкчелегендә һәм мөстәкыйль үзләштерә, сораулар бирә, кызыксына, үз фикерен ачык белдерә. Болар барысы да укучыларның белем алуда шәхескә караган, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләренә ирешүгә һәм универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга хезмәт итә.

Татар теленә өйрәтү заманча технология таләпләре буенча үтәлгәндә гомуми нәтиҗәләр бирә, белем алуга кызыксыну уята. Түбәндәге принципларны катгый үтәгәндә укучыларда кызыксыну уята:

– *дәрестә психологик рәхәтлек, иркенлек тудыру;*

– *тел мохитына “чумдыру” (татарча гына сөйләшү);*

– *чит тел өйрәнү процессын баланың шәхси үсешенә, иҗади сәләтен ачуга юнәлтү;*

– *тел үзләштерүдә табигыйлык юлын сайлау (хаталарын төзәтмичә, дөрес җавапны кабатлау);*

– *минимакс* принцибын саклау (минимум+максимум, алмашып тору үзенчәлегенә ия ике функция мәгънәсендә).

Бу принципларны саклаган очракта түбәндәге бурычлар тормышка аша:

– *укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни, татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән аралашу күнекмәләре булдыру;*

– *коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, киң күңелле әңгәмәдәш булу;*

– *“Татар теле” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну* булдыру һәм, шулар нигезендә, белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерергә шартлар тудыру.

Укытуның **шәхескә бәйле нәтиҗәләре**:

– *шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;*

– *коллективта, төркемнәрдә, парларда эшли алу, аралашу этикеты күнекмәләре формалаштыру, кагыйдәләргә буйсыну, шартларны катгый үтәү күнекмәләре формалаштыру, әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;*

– *төрле тормышчан уен ситуацияләрендә һәм геройларның гамәлләрендә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;*

– *"гаилә", "туган ил", "мәрхәмәтлелек" төшенчәләрен кабул итү, "башкаларга* карата түземлелек, кайгыртучанлык", "кеше кадерен белү" кебек хисләр формалашу.

Укытуның **метапредмет нәтиҗәләре**

***Танып белү нәтиҗәләре:***

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик *фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;*

– *иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;*

– *объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;*

– *төп мәгълүматны аеру, тыңланган мәгълүматның эчтәлеге буенча биремнәр үтәү, бәя бирә белү;*

– *тиешле* мәгълүматны табу өчен аудиодиск тыңлау.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

– *уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;*

– *эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;*

– *эшчәнлек нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;*

– *укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;*

– *ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;*

– *дәрескә кирәкле таләпләрне үти һәм алар белән дөрес эш итә белү;*

– *дәрескә* мөстәкыйль әзерләнә белү һәм уку әсбапларын тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

– *аудиодиск белән эшли белү, аңлап биремнәрне үтәү;*

– *геройларның фикерен тыңлый, аңлый, аңа туры килерлек җавап бирү ;*

– *әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;*

– *аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);*

– *төркемнәрдә, командада, парларда һәм күмәк эшли белү;*

– *мәгълүматны туплау өчен дәрестә активлыкны үстерү*

– *әңгәмәдәшең* белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

Дәрескә керер алдыннан, укытучының исем-фамилиясе, класс, дәреснең үткәрелү вакыты, тикшерүнең (дәрес караунын) максаты билгеләнә. Дәрес тәмамлангач, иң беренче чиратта, укытучының үзанализы тыңлана. Бу вакытта тыңлаучы үзе өчен дәреснең максатларын ачыклый, тагын бер тапкыр дәреснең билгеле бер тәртиптәге (структур) төзелешен, файдаланылган алымнарны күздән кичерә.

Укытучының үзанализын тыңлаганнан соң, дәрес анализлана.

**Дәрес анализлауның гомуми схемасы.**

1. Дәрес максатларының дөрес билгеләнгән булуы, аларның дәрес тибына туры килүе бәяләнә.

**Дәрес максатлары:** белем-күнекмәләр, тәрбия бирү, сәләтне үстерү.

**Дәрес типлары:**

– *лексик күнекмәләр формалаштыру;*

– *грамматик күнекмәләр формалаштыру;*

– *лексик күнекмәләр камилләштерү;*

– *грамматик күнекмәләр камилләштерү;*

– *лексик һәм грамматик күнекмәләр камилләштерү;*

– *диалогик* һәм монологик сөйләм дәресләре (контроль дәресләр).

2. Укытучының куелган дәрес максатларына ирешү эзлеклелеге анализлана. Моның өчен структур анализ ясау кулай. Мәгълүм булганча, дәрес билгеле бер тәртиптә башкарыла торган күнегүләр җыелмасыннан тора. Анализ барышында укучы эшләгән һәр күнегүгә түбәндәге юнәлешләрдә бәя бирелә:

– *күнегү эчтәлегенең дәрес максатларына ярашлылыгы;*

– *күнегүнең вакытлы һәм урынлы файдаланылуы;*

– *күнегү эшләү өчен вакытның дөрес бүлеп бирелүе, гомуми дәрес барышына (динамикасына) ярашлылыгы;*

– *максатта күрсәтелгән сөйләм материалының бу күнегүләрдә өйрәнелү* дәрәҗәсе.

3. Күнегүләрнең сыйфат үзенчәлеген ачыклаганда, аларның бүгенге методика таләпләренә җавап бирү-бирмәве билгеләнә:

– *күнегү биреме фикер йөртү эшчәнлеген күзаллап сайланганмы? Ул гади кабатлауга, ятлауга гына корылмаганмы?*

– *күнегү эчтәлеге аерым бер вакыйга, хәл, күренешне чагылдырамы, әллә ул үзара бәйләнешсез җөмләләрдән гыйбарәтме?*

– *дәрес максатында күрсәтелгән сөйләм материалын үз эченә алган хәлдә, күнегү укучыга нинди дә булса яңалык хәбәр итәме, аның аңының, фикер йөртү дәрәҗәсенең үсешенә уңай йогынты ясыймы?*

– *күнегү* укучының яшь үзенчәлеген искә алып сайланганмы, аның кызыксыну өлкәсен чагылдырамы, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерәме?

4. Дәрес максатында күрсәтелгән сөйләм материалының барлык сөйләм эшчәнлеге төрләрендә (ишетеп аңлау, сөйләшү, уку, язуда) файдаланылуы анализлана. Дәрес максатына карап, сөйләм эшчәнлегенең кайсы төре өстенлек алырга тиешлеге ачыклана.

5. Дәрестә вакытның дөрес бүленү-бүленмәве билгеләнә.

Дәресләрнең тибына карап, төрле күнегүләргә төрлечә вакыт бирелә. Әйтик, лексик күнекмәләр формалаштыру дөрес икән, вакытның күп өлеше яңа лексика белән таныштыруга, аларны элек үзләштерелгән лексик-грамматик структуралар белән бәйләнешкә кертүгә, яңа лексиканы диалогик-монологик сөйләмдә куллану күнекмәләрен үстерүгә багышлана. Бу вакытта телне фән буларак өйрәнүдә ярдәм итүче күнегүләр дә, сөйләм эшчәнлегенә өйрәтү төрендәге күнегүләр дә кулланыла. Ә диалогик-монологик сөйләм дәресләрендә, нигездә, сөйләм теленә өйрәтү төрендәге күнегүләр дәрес максатына ярашлы була.

Вакыт бүленешенә анализ ясаганда, укытучы һәм укучылар сөйләменә сарыф ителгән вакыт чагыштырыла. Укытучы сөйләме дәрес вакытының 10% ыннан артыгын алмаска тиеш.

6. Укучыларның активлык дәрәҗәсе билгеләнә. Моның өчен махсус таблица кулланырга мөмкин.

| | |
|---|---|
| 1?И.Д. | 2.С.Д.? I |

Таблицадагы саннар — укучылар, ә хәрефләр — укучыларның активлык дәрәҗәсен билгеләү өчен махсус тамгалар:

? — сорау бирүдә катнаша;

Җ — сораугa җавап бирә;

А — аудирование (тыңлап аңлау) күнегүләрендә катнаша;

Д — диалогта катнаша;

И — имитатив (охшатып кабатлауга нигезләнгән) күнегүләрдә катнаша һ. б.

Таблицага карап, һәр баланың эшчәнлек төрләрендә катнашу дәрәҗәсен ачыклау уңайлы.

7. Укытучының дәрес үткәрү технологиясе түбәндәгеләрдән чыгып бәяләнә:

– *Сөйләм материалын үзләштерү цикллылыкка (максатка ирешелгән бөтенлеккә) корылганмы?*

– *Дәрестә аралашу ничек оештырыла? Табигый аралашу өстенлек итәме, әллә рольле аралашумы?*

– *Эш оештыру режимы нинди? Фронталь, парлы, төркемнәрдә эшләүнең нисбәте нинди?*

– *Укучыларның уку эшчәнлеге белән идарә итүдә шәхси якын килү ничек оештырыла? Аның нинди төрләре кулланыла?*

– *Билге кую, бәяләү рәвеше дөрес сайланганмы? Билге куюда укучыны белем алу белен кызыксындыру искә алынамы?*

– *Күрсәтмә чаралар уңышлы, максатка ярашлы итеп кулланыламы?*

– *Укучыларның сөйләм хаталарын төзәтү ысуллары дөрес сайланганмы?*

– *Укытучы уку эшчәнлеген оештыру турындагы күрсәтмәләрне дөрес бирәме?*

– *Өй эшенә* таләпләр дөрес үтәләме?

Анализ вакытында шулай ук **дәреснең психологик-педагогик яктан дөрес оештырылуына** да игътибар итәргә кирәк. Нигездә түбәндәгеләр искә алына:

– *Укучыларның фикерләү сәләтен үстерү юнәлешендә эш алып барылдымы? Дәрестә иҗади фикерләүгә нигезләнгән күнегүләр башкарылдымы?*

– *Уку эшчәнлеге хәтернең нинди төренә нигезләп алып барылды? Ихтыяри (произвольное) хәтер белән ихтыярсыз (непроизвольное) хәтернең нисбәте нинди?*

– *Укуга теләк уятуның һәм мәҗбүр итеп укытуның нисбәте нинди булды?*

*– Тел өйрәнү барышында укучыларның мөстәкыйльлеге ни дәрәҗәдә булды? Мөстәкыйльлек үстерүнең нинди ысуллары файдаланылды? Үзконтроль, үзара контроль ни рәвешле оештырылды?*

*– Укытучы үз-үзен культуралы тотамы, йөз, гәүдә хәрәкәтләре килешле булдымы?*

*– Укучылар уку эшчәнлеген оештыра белергә өйрәтелдеме?*

– *Дәреснең* тәрбияви максаты ничек тормышка ашырылды?

Дәрес анализлау, әйткәнебезчә, гаять катлаулы эш. Ачык дәрестән соң, 10—15 минут дәвамында “дәреснең бу өлеше ошады, бу өлеше ошамады” дәрәҗәсендә бәя бирү анализның объектив эчтәлеген югалта.

Югарыда күрсәтелгән схема буенча хезмәттәшләрнең генә түгел, үз дәресләреңне дә анализларга мөмкин. Болай эшләгәндә, укытучының дәрес бирү тәҗрибәсе байый, камилләшә, фәнниләшә. Ә бу үз чиратында укыту процессын оештыруның нәтиҗәлелеген күтәрә.

Дәрес анализлауның максаты — укытучы эшендәге кимчелекле якларны эзләп табу түгел, бәлки дөреслекне ачыклап, аңа эшлекле ярдәм күрсәтү. Һәр мөгаллим аралашуда әдәп нормаларын сакларга бурычлы.

# ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. 2016/2017 нче уку елында Татарстан Республикасында рус телендә гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбиятын укыту үзенчәлекләре. Дәресләрнең технологик карталары / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р. Р., Мөхәрләмова Г. Н., Фәттахова Р. Ф., Һадиева Г. В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 69 б.
2. 2016/2017 нче уку елында Татарстан Республикасында татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар телен укыту үзенчәлекләре. Дәресләрнең технологик карталары / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р. Р., Мөхәрләмова Г. Н., Фәттахова Р. Ф., Һадиева Г. В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 36 б.
3. IX сыйныф укучыларын татар теленнән Бердәм республика тестын үтүгә әзерләү (текст белән эшләү методикасы)/авт.-төз.: Гыйләҗева Л. Г., Һадиева Г. В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 34 б.
4. Гильманов Д. Ш. Уроки татарского языка на основе предметных действий: для русскоязычных детей дошкольного и младшего школьного возраста. — Казань: ГАОУ ДПО ИРО РТ, 2016. — 75 с.
5. Заманча технологияләргә нигезләнгән татар теле һәм әдәбияты дәресләре (ТР Лаеш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән)/ Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р. Р., Мөхәрләмова Г. Н., Һадиева Г. В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 88 б.
6. Изложение язуга әзерлек: татар теле һәм әдәбияты буенча башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогик хезмәткәрләр өчен методик ярдәмлек / авт.-төз. М. Г. Мозаффарова. — Казан: ТРМҮИ. — 35 б.
7. Мозаффарова М.Г. Тәгълим-тәрбия процессын оештыруда милли мәгърифәтчелек идеяләрен гамәлгә кую: гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре өчен тәкъдимнәр. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 56 б.
8. Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар теле буенча олимпиадага әзерләнү өчен биремнәр / Төзүче: Р. Р. Шәмсетдинова. — Казан, 2016. — 17 б.

9. Татар теле дәреслекләренә электрон кушымталар. Методик ярдәмлек / Төзүчеләр: Р. Р. Шәмсетдинова, А. А. Бәшәрова. — Казан: ТРМҮИ, 2015. — 68 б.
10. Татар телен өйрәнү өчен укучыларны төркемнәргә бүлү буенча тәкъдимнәр: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының I сыйныфлары өчен. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда уен технологияләре (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р. Р., Фәттахова Р. Ф., Мөхәрләмова Г. Н., Һадиева Г. В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 23 б.
11. Татар телен һәм әдәбиятын заман таләпләре буенча укытабыз (ТР Бөгелмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының тәҗрибәсеннән. /Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р. Р., Мөхәрләмова Г. Н., Һадиева Г. В., Мәхмүтова Ф. Т. — Казан: ТРМҮИ, 2015. — 160 б.
12. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда коммуникатив технологияләр (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р. Р., Фәттахова Р. Ф., Мөхәрләмова Г. Н., Һадиева Г. В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 53 б.
13. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда уен технологияләре (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р. Р., Фәттахова Р. Ф., Мөхәрләмова Г. Н., Һадиева Г. В. Казан: ТРМҮИ, 2016. — 55 б.
14. Фаттахова Р. Ф. Практический татарский язык: методическое пособие для изучающих татарский язык. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. — 176 с.
15. Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (5 нче сыйныф өчен "Татар әдәбияты" предметы буенча эш программасы). — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. — 94 б.
16. Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (5 нче сыйныф өчен "Татар теле" предметы буенча эш программасы). — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. — 136 б.
17. Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (6 нчы сыйныф өчен “Татар теле”, “Татар әдәбияты” буенча

эш программалары). 1 кисәк. — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2016. — 108 б.
18. Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (6 нчы сыйныф өчен “Татар теле”, “Татар әдәбияты” буенча эш программалары). 2 кисәк. — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2016. — 108 б.
19. Шамсутдинова Р. Р., Фаттахова Р. Ф. Методические рекомендации по преподаванию предметов «Татарский язык и литература». — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 39 б.
20. Мухарлямова Г. Н., Фаттахова Р. Ф., Сиразетдинова З. П. и др. Методические рекомендации по составлению рабочих программ для 7 классов общеобразовательных организаций (с обучением на русском языке). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 44 б.
21. Мухарлямова Г. Н, Гилязова Л. Г., Валиева М. Н. и др. Методические рекомендации по составлению рабочих программ для 7 классов общеобразовательных организаций (с обучением на татарском языке). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 39 б.
22. Мухарлямова Г. Н, Хадиева Г. В., Ханнанова М. Х. и др. Методические рекомендации по составлению рабочих программ для 7 классов общеобразовательных организаций (с обучением на русском языке для изучающих татарский язык как родной). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 67 б.
23. Рабочие программы по татарскому языку для образовательных организаций СПО (4 наименований). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 20 с.; 18 с.; 15 с.; 20 с.
24. Шамсутдинова Р. Р., Зиннатуллин Р. К., Фаттахова Р. Ф., Гилязова Л. Г., Хадиева Г. В. Современные технологии в обучении татарскому языку и литературе. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 94 б.
25. Шамсутдинова Р. Р., Фаттахова Р. Ф., Гилязова Л. Г., Хадиева Г. В. Сборник текстов и заданий для проведения контрольных работ по татарскому языку. Казан, ТРМҮИ, 2017. — 28 б.
26. Шамсутдинова Р. Р., Фаттахова Р. Ф., Гилязова Л. Г., Хадиева Г. В. Сборник заданий школьного, муниципального и республиканского туров олимпиад по татарскому языку для русскоязычных обучающихся. Казан, ТРМҮИ, 2017. — 33 б.

27. Шамсутдинова Р. Р., Фаттахова Р. Ф., Гилязова Л. Г., Хадиева Г. В. Сборник татарских версий КИМ и тренировочных заданий ОГЭ по предметам.
28. Шамсутдинова Р. Р., Фаттахова Р. Ф., Гилязова Л. Г., Хадиева Г. В. Сборник КИМ для мониторинга знаний обучающихся русскоязычных групп 4, 6, 8 классов по татарскому языку. Казан, ТРМҮИ, 2017. — 39 б.
29. Карпухина Н. И. Сборник контрольных работ (по УМК «Сәлам!»). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 52 б.
30. Шамсутдинова Р. Р. Методические рекомендации по подготовке к олимпиадам по татарскому языку русскоязычных учащихся. — ТРМҮИ, 2016. — 36 б.

## ИНТЕРНЕТ РЕСУРСЛАРЫ

http://минобрнауки.рф (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы);
http://www.edu.ru («Российское образование» федераль порталы);
http://mon.tatarstan.ru (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы);
http://www.irort.ru (ТРМәгарифне үстерү институты)
http://www.fasi.gov.ru Фән һәм инновацияләр буенча федераль агентлык
http://www.obrnadzor.gov.ru Рособрнадзор
http://www.apkppro.ru РФ мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм профессиональ әзерләү академиясе
http://www.lexed.ru Федеральный центр образовательного законодательства
http://www.rustest.ru Федераль тест үткәрү үзәге
http://www. tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы
http://www.edu. kzn.ru Казан шәһәре Белем порталы
http://www.it-n.ru http://belem.ru
http:// tatcenter.ru ТР мәгълүмати-аналитик порталы
http:// Tat. Tatar-inform.ru ТР мәгълүмат агентлыгы
http:// intertat.ru ТР электрон газетасы
http://suzlek.ru on-line русча сүзлеге
http://Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://Tatar.com.ru татар телендә сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр
http:// Tatarca.boom.ru татарча текстлар

## ЭЧТӘЛЕК

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы эшчәнлеген билгели торган норматив документлар.......................................... 3

Татар телен туган тел буларак һәм әдәбиятны укыту......... 7

“Туган тел (татар теле)” һәм “Әдәбият (татар әдәбияты)” уку предметларын укытуны тәэмин итә торган укыту-методик комплексларына күзәтү .........................17

"Туган тел (татар теле)” һәм “Әдәбият (татар әдәбияты)” предметлары буенча планлаштырган нәтиҗәләргә ирешү 40

Тәкъдим ителгән әдәбият исемлеге ..............................49

Интернет ресурслары ..................................................53

# ПАРТНЕРЫ ИНСТИТУТА

РОССИЙСКАЯ АКАДЕМИЯ ОБРАЗОВАНИЯ

UNESCO
United Nations Educational, Scientific and Cultural Organization

IITE
UNESCO Institute for Information Technologies in Education

ЦЕНТР РЕАЛИЗАЦИИ ГОСУДАРСТВЕННОЙ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЙ ПОЛИТИКИ И ИНФОРМАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ

Sk Сколково

СИРИУС
ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫЙ ЦЕНТР

Казанский федеральный УНИВЕРСИТЕТ

Российский университет дружбы народов
RUDN University

НГПУ
НАБЕРЕЖНОЧЕЛНИНСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ

МОСКОВСКИЙ ГОРОДСКОЙ УНИВЕРСИТЕТ
МГПУ

ШКОЛЬНАЯ ЛИГА РОСНАНО

РАНХиГС

АГЕНТСТВО СТРАТЕГИЧЕСКИХ ИНИЦИАТИВ

Общероссийская общественная организация
АССОЦИАЦИЯ УЧИТЕЛЕЙ ИСТОРИИ И ОБЩЕСТВОЗНАНИЯ

it park

ВЫСШАЯ ШКОЛА ЭКОНОМИКИ
НАЦИОНАЛЬНЫЙ ИССЛЕДОВАТЕЛЬСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ

СМП РТ
СОВЕТ МОЛОДЫХ ПЕДАГОГОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ассоциация школьных психологов РТ
Параллель

УНИВЕРСИТЕТ ТАЛАНТОВ
КАЗАНЬ

1890
КНИТУ

Издательство «Русское слово»

УЧЕБНАЯ ЛИТЕРАТУРА
ИЗДАТЕЛЬСТВО

МӘГАРИФ
education

ДРОФА вентана граф
ОБЪЕДИНЕННАЯ ИЗДАТЕЛЬСКАЯ ГРУППА

АКАДЕМКНИГА/УЧЕБНИК

ФИЗИКОН
www.multiring.ru

ИЗДАТЕЛЬСТВО
НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

ПРОСВЕЩЕНИЕ

2019/2020 нче уку елында
“ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)”
һәм “ӘДӘБИЯТ (ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ)”
укытуның актуаль мәсьәләләре

Форм.бум.60х84 1/16. Усл.п.л. 3,4
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ
420015 Казан, Зур Кызыл ур., 68
Тел.: (843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42 E-mail:
irort2011@gmail.com